КЕСӘ КАЙГЫСЫ

Бүген банкта кертем ачу отышлымы?

> 5

ГОМЕРЛЕК ҮКЕНЕЧ

Татарстанда абортларга каршы яңача көрәшмәкчеләр

> 15

ЛИЛИЯ ФӘТТАХОВА:

«Җәмгыятьне сүгеп кенә үзгәртеп булмый»

> 18–19

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 126 (29093) | Җомга | 1 сентябрь | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

ХӘЕРЛЕ СӘГАТЬТӘ!

ЯҢА УКУ ЕЛЫНА – ЯҢА МӘКТӘПЛӘР

Бүген мәктәпләрдә беренче кыңгырау чыңлый. Тырышып укырга көч биреп, ел дәвамында бары сөенечле хәбәрләр генә китерә торган чың булсын иде ул. Белем көне шатлыклы вакыйгалардан башлана. Татарстанда 1 нче сыйныфка 57 мең бала керә. Барлыгы 11 яңа мәктәп ачыла. Шәһәр генә түгел, районнарда да ун меңгә якын яңа урын булдырылган дигән сүз бу. Дөрес, хәл итәсе мәсьәләләр дә бар.

> 7

БЕЛЕМ КӨНЕ БЕЛӘН!

Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм МИҢНЕХАНОВның Белем көне уңаеннан МӨРӘҖӘГАТЕ

Хөрмәтле татарстанлылар!

Кадерле укытучылар һәм мәгариф өлкәсе хезмәткәрләре, укучылар һәм студентлар!

Барлык укытучыларны, педагогларны, остазларны, тәрбиячеләрне, мәгариф системасы ветераннарын, шулай ук студентларны, мәктәп укучыларын һәм аларның ата-аналарын Белем көне – якты өметләр, балаларның һәм өлкәннәрнең елмаюлары, көтелгән очрашулар шатлыгы, ә иң мөһиме – белемгә омтылыш хисләре белән тулы зур бәйрәм уңаеннан тәбрик итәм.

Тантаналы бу көндә безгә белем ишекләрен ачкан укытучыларга рәхмәт сүзләребезне җиткерәбез. Аларның тырыш хезмәте нәтиҗәсендә балалар укуда, спортта һәм сәнгатьтә уңышларга ирешә, олимпиадаларда, төрле бәйгеләрдә һәм конкурсларда җиңү яулый.

Укытучыларның, сыйныф җитәкчеләренең һәрбер укучы иң биек үрләргә күтәрелергә сәләтле дигән какшамас ышанычы бар, алар балаларга тормышта кирәк булачак күнекмәләр бирүне максат итеп куя. Югары уку йортлары укытучылары студентларга мәгърифәти һәм фәнни тикшеренүләрендә тәҗрибәле җитәкче булып, фән, техника, сәнгать, җитештерү өлкәләрендә яңа офыклар ачардай белгечләр әзерли.

Мәгариф хезмәткәрләре – укучылары өчен юл күрсәтүче, белем һәм тәҗрибә белән уртаклашучы. Ватан язмышын кайгыртып, үзендә җаваплылык тойган камил шәхес тәрбияләүгә өлеш керткән һәрбер укытучы хезмәтенең кыйммәтен без яхшы аңлыйбыз. Россия Федерациясе Президенты Владимир Владимирович Путин Указы нигезендә Россиядә игълан ителгән Укытучы һәм остаз елы аларның җәмгыятьтәге зур ролен тануга ачык дәлил булып тора.

Республикада барлыгы 80 мең педагог миллионга якын балага белем бирә. Үз нәүбәтендә дәүләт укытучыларның һөнәри үсешен тәэмин итүгә һәм эш шартларын яхшыртуга мөмкинлекләр тудыра. Без укытуның сыйфатын күтәрү өчен технологияле һәм инновацияле мохит булдырырга омтылабыз.

Яшь буынга ватанпәрвәрлеккә, республикабыз һәм илебез өчен традицион рухи-әхлакый хәзинәләргә нигезләнеп тәрбия бирү – уртак бурычыбыз.

1 сентябрь – беренче сыйныфка баручы сабыйлар һәм аларның әти-әниләре өчен аеруча дулкынландыргыч көн. Мәктәпкә керү – һәр баланың тормышында гаять әһәмиятле вакыйга. Бүген меңәрләгән бала мәктәп бусагасын тәүге кат атлап керә, алар өчен беренче тапкыр дәрескә чакырып кыңгырау чыңлаячак. Яшь буыныбызның илебезнең патриотлары һәм лаеклы гражданнары булып үсәчәгенә шигем юк. Кадерле балалар, укуыгызда уңышлар юлдаш булсын, күңелегездә иҗат илһамы сүнмәсен! Хәерле сәгатьтә!

Хөрмәтле татарстанлылар! Хәзерге заманда белемнең артыгы юк, һәрбер яңа күнекмә фикер офыклары киңәюгә, казанышларга ирешүгә ярдәм итә. Гыйлем үзләштерүдә ару-талуны белмәгез!

Сезгә бәхет, тынычлык, иминлек һәм игелек телим! Бәйрәм мөбарәк булсын!

Онытылмыйлар

Казанда Әнвәр Баһаветдинов хөрмәтенә хәтер тактасы ачылды. 1983–1986 елларда – ТАССР Югары Советы Президиумы Рәисе, 1984–1986 елларда РСФСР Югары Советы Президиумы Рәисе урынбасары булып эшләгән дәүләт эшлеклесен искә алырга республика җитәкчелеге һәм Әнвәр Баһаветдиновның туганнары килде.

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Әнвәр Баһаветдиновның республика һәм Россия тарихында тирән эз калдырганын, һөнәри осталыгы, сәяси таланты һәм зирәклеге аркасында хезмәттәшләренең аны аксакал дип йөрткәннәрен искә алды. Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев сүзләренчә, Әнвәр Баһаветдинов үткен акыл, иплелек, тырышлык һәм бетмәс-төкәнмәс энергиягә ия шәхес иде. «Аның белән эшләү минем өчен зур мәртәбә иде. Әнвәр Бәдретдин улы – Ватанга хезмәт итүнең чын үрнәге. Ул республикабыз һәм илебез чәчәк атсын дип эшләде», – диде Дәүләт Киңәшчесе.

Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин әйтүенчә, үз вакытында аңа Әлмәттә Әнвәр Бәдретдин улы белән бергә эшләү бәхете тигән, 1970 нче еллар ахырында ул шәһәр партия комитетының беренче секретаре итеп сайланган. Фәрит Мөхәммәтшин сүзләренә караганда, Дәүләт Советы эше бүген дә Әнвәр Баһаветдинов эшләгән елларда салынган нигезгә таянып алып барыла. «Әнвәр Бәдретдин улы барысын да иҗади эшкә юнәлдерә белде», – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

Ният бар

Бар кыйтгада белсеннәр! Бәйрәм көнне Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Мексика, Катар, Казахстан, Замбия илчеләре белән очрашты.

«Безнең илләр – стратегик хезмәттәшләр. Бүгенге катлаулы заманда Мексиканың үз позициясе бар һәм без моны югары бәялибез», – диде Рөстәм Миңнеханов бу илнең Россиядәге гадәттән тыш һәм тулы вәкаләтле илчесе Эдуардо Вильегас Мехиас белән очрашуда. Россия белән Мексика арасындагы хезмәттәшлекне акчага күчереп санасак, әлеге күрсәткеч 4 миллиард долларга җитә. Рөстәм Миңнеханов фикеренчә, Татарстан да Мексика белән элемтәләрне ныгытырга тели. Эдуардо Вильегас Мехиас әйтүенчә, алар ике якка да файдалы булырлык мөмкинлекләрне өйрәнәчәк.

Рөстәм Миңнеханов сүзләренә караганда, Катар – Якын Көнчыгыш төбәгендә Россиянең иң мөһим партнеры. Ике арада сәүдә-икътисадый, мәдәни-гуманитар һәм фәнни-техник хезмәттәшлек үсә. Бу эшкә Татарстан да үз өлешен кертергә тырыша. Катар дәүләтенең Россиядәге гадәттән тыш һәм тулы вәкаләтле илчесе Шәех Әхмәт бин Нассер бин Җәссим Әл-Тани белән очрашуда Рөстәм Миңнеханов ике арадагы хезмәттәшлекне үстерү өчен мөмкинлекләр барлыгын әйтте. Илче дә элемтәләрне ныгытырга әзер булуларын әйтте.

30 августта Казахстанда Конституция көнен билгеләп үттеләр. Рөстәм Миңнеханов бу илнең Россиядәге гадәттән тыш һәм тулы вәкаләтле илчесе Даурен Абаевны бәйрәм белән котлады. Даурен Абаев исә Рөстәм Миңнехановка Казахстан Президентының котлау сүзләрен җиткерде. «Уртак тырышлык, дуслык һәм үзара ярдәмләшү традицияләре ярдәмендә Казахстан белән Татарстан арасындагы хезмәттәшлек киләчәктә дә безнең халыклар файдасына үсеш алачак», – диелә котлауда. «Безнең илләрнең аерым мөнәсәбәтләре бар. Тиз үзгәрә торган хәзерге катлаулы шартларда икътисадны үстерү өчен яңа юллар эзләргә кирәк», – диде Татарстан Рәисе очрашуда. Узган ел Татарстан белән Казахстан арасындагы товар әйләнеше 758 миллион долларны тәшкил иткән. 2023 елның беренче өч аенда үсеш 45 процент булган.

Замбиянең Россиядәге гадәттән тыш һәм тулы вәкаләтле илчесе Шедрек Чингемб Лувита белән очрашуда Рөстәм Миңнеханов Африканың дөнья икътисадында һәм халыкара мөнәсәбәтләрдә урыны ныгый баруын әйтте. Мөмкинлекләр булса да, Татарстан белән бу ил бөтенләй диярлек хезмәттәшлек итми. Яклар, хезмәттәшлек өчен өметле юнәлешләрне билгеләү ниятеннән, Сәнәгать һәм Сәүдә министрлыклары дәрәҗәсендә очрашу турында килештеләр.

БҮЛӘКЛЕ БӘЙРӘМ

tatarstan.ru

38 нче мәртәбә оештырылган «Уйнагыз, гармуннар!» фестиваленә быел 30 төбәктән 700 катнашучы җыелды. Камал театры каршындагы мәйданда өч сәгатьлек концерттан соң гармунчылар Кремльгә таба кузгалды. Аннары Кремль яр буенда янә җыр-моң белән сөендерделәр. Быелгы парадны Татарстанның атказанган артисты Илсөя Бәдретдинова җитәкләде.

Төзекләндерелгән Казансу яр буе, бөтен уңайлыклары булган парк, булачак рәссамнарга – яңа йорт. Татарстан Республикасы көне уңаеннан башкалада төзекләндерелгән һәм яңа төзелгән биналар, җәмәгать урыннары ачылды. Аларны Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та карады.

Рәис Фешин исемендәге Казан сәнгать училищесының яңартылган бинасында булды. Бирегә шулай ук Татарстан Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев һәм Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин да килде. Сәнгать училищесы бинасы федераль әһәмияттәге шәһәр төзелеше һәм архитектура һәйкәле булып санала. Аны төзекләндерү һәм реставрацияләү 2019 елда ук башланган иде. Рөстәм Миңнехановка реставрация этаплары һәм аның катлаулылыгы, эш барышы турында сөйләделәр. Аерым алганда, Рәис үзәк баскыч һәм култыкса элементларын торгызуга бәйле башкарылган эшләр белән танышты. Билгеле булганча, бина үзенчәлекле архитектура элементлары белән аерылып тора. Мәсәлән, түбәдәге пыяла чатырдан төшкән яктылык бинаның барлык катларына үтеп керә. Бүген Казан сәнгать училищесы – ил күләмендә иң борынгы белем бирү йортларының берсе. Анда 254 студент белем ала.

Рөстәм Миңнеханов «Казан» гаилә үзәгеннән Кремльгә кадәр төзекләндерелгән Казансу яр буенда да йөрде. Анда велосипедта йөрүчеләр һәм җәяүлеләр өчен яңа юллар барлыкка килгән, яр буен яшелләндергәннәр. Төзекләндерелгән яр буенда 3,7 меңгә якын агач һәм куак утыртканнар. Биредә велосипедта йөрү, йөгерү, спорт марафоннары үткәрү дә каралган.

Рәис Казан Кремленең яңартылган Спас манарасын да карады. Төзекләндерүдән соң анда музей ачылган. Ул кирмән белән Спас манарасы тарихына багышланган. Манара туристлар өчен инде ачык.

«Светлая Долина» торак комплексында яшәүчеләр өчен дә 30 август икеләтә бәйрәмгә әверелде. Анда яңа парк ачылды. Җәмәгать урыны Казанның Совет районында Нокса елгасының уң як ярында урнашкан, территориясе Кече Клыки бистәсе белән чиктәш. Янәшәдән төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлы – Мамадыш тракты да үтә. Паркта җәяү йөрү, воркаут, барбекю зоналары, спорт мәйданчыклары, самокатта йөрү юллары һәм ял итү өчен башка урыннар да бар. Түбәсе ябылган мәйданда пинг-понг яки шахмат уйнарга мөмкин булса, тыныч почмакта йога белән шөгыльләнеп була.

Биредә үк Рөстәм Миңнеханов Мәхмүтов исемендәге 184 нче номерлы «Киләчәк» гимназиясенә дә кереп чыкты. 2018 елдан 2023 елга кадәр гимназиядә балалар саны биш тапкыр арткан. Хәзер биредә 2138 укучы исәпләнә. Гимназиядә Рәис уку сыйныфларын, остаханәләрне, актлар залын карады. Рөстәм Миңнеханов ашханәгә дә кереп чыкты. Аны балаларга тәкъдим ителүче ризыклар белән сыйладылар. Бәйрәм уңаеннан бүләк тә бар: Рәис гимназиядә белем бирүче яшь педагогларга ноутбуклар тапшырды.

Бәйрәм алдыннан узган тантаналы чараларда Россия Президентының Идел буе федераль округындагы тулы вәкаләтле вәкиле Игорь Комаров та катнашты. «Республикага килгән саен биредә күп эш башкарылганына инанасың. Тиешле игътибар бирелмәгән бер генә тармак та юк. Бары җәйга салынган көндәлек эш белән генә мондый уңышка ирешеп була», – диде ул һәм эшләргә генә түгел, уңышларны күреп, шуңа сөенергә дә киңәш итте. Идел буе Болгарында ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулуны бәйрәм итүгә әзерлек һәм үткәрүдәге казанышлары өчен Игорь Комаров Рөстәм Миңнехановка Россия Президентының Рәхмәтен тапшырды.

АБРУЙЛЫ ҖЫЕН

Казан кабат ил төбәкләре һәм чит ил вәкилләре өчен очрашу мәйданына әверелде. Башкалада Татарстан нефть һәм газ химиясе форумы һәм TatOilExpo – 2023 халыкара күргәзмәсе уза.

Ачылыш тантанасында Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов быелгы форумның республикада нефть чыгара башлауның 80 еллыгына багышлануын әйтте.

– Инде 30 ел дәвамында Нефть һәм газ сәнәгате хезмәткәрләре көнен бәйрәм итәр алдыннан безнең республика зур халыкара нефть һәм газ сәнәгате форумын үткәрү урынына әверелә, – диде ул.

Быел форумда илнең 27 төбәгеннән һәм чит илләрдән 180нән артык компания катнаша. Рөстәм Миңнеханов шундый катлаулы вакытта Татарстанга килгән чит ил кунакларына рәхмәт белдерде.

– Үзара хезмәттәшлек һәм фикер алышулар дусларча элемтәләрне үстерүгә яңа этәргеч бирер дип ышанам, – диде ул.

Рөстәм Миңнеханов фикеренчә, җыен мәйданы ике якка да файдалы хезмәттәшлекне дәвам иттерү, яңа эшлекле элемтәләр булдыру, дөнья икътисады кризисы нәтиҗәләрен юкка чыгаруда көчләрне берләштерү өчен нәтиҗәле корал булачак.

TatOilExpo – 2023 күргәзмәсендә Рәискә нефть һәм газ химиясе җиһазлары һәм технологияләре өлкәсендә яңалыкларны тәкъдим иттеләр. Мәсәлән, ул Казан моторлар төзү берләшмәсендә җитештерелә торган продукция – газ-турбина двигательләре, газ суырту агрегатлары, газ-турбина энергетика җайланмалары белән танышты. «Химград» технополисы ирешкән икътисадый күрсәткечләр һәм алдагы эшләр турында сөйләде. Аерым алганда, Үзбәкстандагы проектларга зур өметләр баглыйлар.

Җыенның пленар утырышында Россия нефть һәм газ компанияләренең үсеш мөмкинлекләре турында сөйләштеләр.

– Татарстан нефть һәм газ химиясе форумы абруйлы халыкара чарага әверелде, – диде җыенда катнашучыларны видеоэлемтә аша сәламләгәндә Россия вице-премьеры Александр Новак. – Форум тармакның төп катнашучыларын берләштерә, фикер алышу, көн кадагындагы мәсьәләләргә җавап эзләү, шулай ук эшчәнлекне тагын да камилләштерү өчен үзенчәлекле мәйдан булып тора.

Рөстәм Миңнеханов билгеләп үткәнчә, Татарстанда сәнәгатьнең 62 проценты нефть һәм газ химиясе тармагына туры килә. Республика – сәнәгать җитештерүе өлкәсендә әйдәп баручы төбәкләрнең берсе, диде ул.

– Без 80 елдан бирле нефть чыгарабыз. 3,5 миллион тонна «кара алтын»ны җир өстенә күтәрдек инде. Бу юнәлештә тагын 200–300 ел эшләү мөмкинлеге бар, – диде Рәис.

Рөстәм Миңнеханов ассызыклаганча, «Татнефть» компаниясе чит ил компанияләре тәкъдимнәренә дә карамастан, үзебезнең ил җиһазлары ярдәмендә гаять ябышкак нефть чыгаруны җайга сала алды.

– Фән ул – нигез. Аның ярдәмендә катализаторлар, авыр компонентлар кебек күпчелек катлаулы проблемаларны хәл итә алдык. Фәнгә аеруча зур игътибар бирергә кирәк, – диде Рәис.

Аның фикеренчә, дәүләттән кызыксындыру чаралары да мөһим. Югыйсә бу өлкәдә кайбер аңлашылмаучанлыклар бар.

– Гаять ябышкак нефть турында сөйлибез икән, аны чыгару юллары төрле булуга да карамастан, салым бер үк дәрәҗәдә диярлек. Бу гаделме? – диде Рөстәм Миңнеханов.

Форум әнә шундый борчыган мәсьәләләрне уртага салып сөйләшү өчен кирәк тә инде. Җыен кысасында күпсанлы эшлекле очрашулар һәм сөйләшүләр, республика нефть химиясе продукциясен төзелеш тармагында, юл төзелешендә куллануны киңәйтү кебек темалар буенча «түгәрәк өстәл»ләр уздыру да каралган. Ул иртәгәгә кадәр дәвам итәчәк.

Татарстан Рәисе форум кысасында Беларусь премьер-министры урынбасары Петр Пархомчик, Бәхрәйн Корольлегенең нефть һәм әйләнә-тирә мохит министры доктор Мөхәммәд бән Мөбарәк бән Даина, Анголаның Россиядәге гадәттән тыш һәм тулы вәкаләтле илчесе Аугушту да Силва Куньа белән очрашты.

ЯШЬЛӘР ӨЧЕН – ЯШЬЛӘР ТЕЛЕНДӘ

КАЗАНДА ЯШЬ БУЫН КИЛӘЧӘГЕ ТУРЫНДА ФИКЕР АЛЫШТЫЛАР

Телләр, илләр төрле, максат бер. Бу атнада Казан, дөньяның төрле почмакларыннан килгән делегатларны берләштереп, фикер алышу, тәҗрибә алмашу мәйданчыгына әверелде. Республика башкаласында икенче тапкыр Глобаль яшьләр саммиты узды. Бу юлы 30 дәүләттән 140лап делегат, хакимият вәкилләре нәрсә турында сөйләште?

Фикер алышу үзәгендә – гаилә, традицион кыйммәтләр, үсеп килүче буынны тәрбияләү мәсьәләсе, милли үзенчәлек, халыклар дуслыгы. Аерым игътибарда – интернетның йогынтысы.

Татарстанда бу юнәлештә башкарылган эшләр дә җитәрлек. Шуңа республиканы мактадылар. Россия Президентының Идел буе федераль округындагы тулы вәкаләтле вәкиле Игорь Комаров билгеләп үткәнчә, Татарстан үсеп килүче буынны тәрбияләүгә аеруча җаваплы карый. Гомумән, традицион кыйммәтләр күптәннән ил нигезендә ята инде.

– Илебез традицион кыйммәтләрне Россия җәмгыятенең үсеш нигезе итеп күрә, ул суверенитетны ныгытырга, күпмилләтле һәм күпконфессияле илебезнең бердәмлеген тәэмин итәргә мөмкинлек бирә, – диде ул. – Мәгариф, тәрбия һәм яшьләр белән эшләү өлкәләре Россия Президенты Владимир Путин тарафыннан традицион кыйммәтләрне саклау һәм ныгыту буенча дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләренең берсе буларак билгеләнә. Россия, гуманистик традицион кыйммәтләргә ия булган дәүләтләр белән бергә, цивилизациянең мәдәни һәм этик нигезен җимерүче, кыйммәтләрне дә, кешенең табигатен дә үзгәртергә тырышуларга каршы тора. Бу көрәш хәзер күп юнәлешләрдә һәм төрле өлкәләрдә алып барыла. Үсеп килүче буынны тәрбияләү өлкәсе – моңа каршы торуның иң мөһим юнәлеше.

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов исә яшь буын үсешенә йогынты ясаган интернет мәсьәләсенә игътибар итте. Аның әйтүенчә, шәхес формалашуында «сәламәт кыйммәтләр» кирәк. Әмма интернет – еш кына ак белән караны бутаучы.

– Интернеттагы күренешләргә җавап бирмәсәк, соңрак алар психик тайпылышларга, шәхес тормышын куркыныч астына куючы күренешләргә әверелергә мөмкин, – диде Рөстәм Миңнеханов.

2030 елга Җир шарында яшәүче халыкның 23 процентын яшьләр тәшкил итәчәк. Моңа кадәр бер адым алда барып, вакыттан файдаланып, аларны дөрес юнәлештә тәрбияләргә кирәк. Ислам дөньясының мәгариф, фән һәм мәдәният мәсьәләләре буенча оешмасы генераль директоры, доктор Сәлим бин Мөхәммәт әл-Малик шундый фикерен җиткерде.

– Яшьләрнең киләчәген кайгыртучы булмаса, алар үзләре үз киләчәген билгеләмәсә, бу эшне бүтәннәр башкарачак. Алар исә моңа үз мәнфәгатьләреннән чыгып, үзгәрешләр кертергә тырышачак, – диде ул.

Быелгы саммитта Ливия, Фәләстыйн, Сенегал, Ливан, Камерун, Таҗикстан илләренең яшьләр белән эшләүче оешма вәкилләре, министрлар, Ислам Хезмәттәшлеге Оешмасы Генераль Секретариаты, Ислам дөньясының мәгариф, фән һәм мәдәният мәсьәләләре буенча оешмасы (ИСЕСКО), ислам тарихын, мәдәниятен һәм сәнгатен өйрәнү буенча халыкара фәнни-тикшеренү үзәге (ИРСИКА), фәнни һәм технологик хезмәттәшлек буенча даими комитет (КОМСТЕХ), ОИС яшьләр форумы җитәкчеләре һәм вәкилләре катнашты.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Каерылмасын канатлары!

Кош гриппы Татарстанга да килеп җитте. 25 августта Лениногорск кош фабрикасында күпләп тавыклар үлә башлаган. Алардан пробалар алгач, кошларда куркыныч һәм йогышлы авыру булуы ачыкланган. Инфекцияне читкә таратмас өчен, оешмадагы барлык кошлар да юк ителгән һәм 55 чакрым радиустагы территориягә карантин кертелгән.

Әлеге зонага республиканың тугыз районы (Лениногорск, Азнакай, Әлмәт, Баулы, Бөгелмә, Зәй, Сарман, Чирмешән һәм Ютазы) керә. Бу турыда Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнехановның указы чыкты.

Фабрикадагы барлык кош – 220 мең тавык юк ителде, үлгән тавыкларны яндырдылар. Авыру кошларны дәвалау шулай ук тыела. Моннан тыш, Татарстан Рәисе указы нигезендә, кош һәм йомырка, теләсә нинди кош продукциясен, азыгын кертү һәм алып чыгу тыела. Кош фабрикасы генераль директоры барлык эшчеләрен дә вакциналауны оештырырга тиеш.

Аеруча куркыныч булган зонага Лениногорск шәһәре, Тимәш, Савочкино авыллары, Вәлиев бистәсе кергән. Биредә кош һәм йомырка кертү һәм чыгару, ризык әзерләү, кошларны урамга чыгарып йөртү, аулау һәм авыл хуҗалыгы ярминкәләре уздыру тыела.

Исегезгә төшерәбез: 9 августта әлеге куркыныч авыру якын күршебез Башкортстанның «Башкирская» кош фабрикасында чыккан иде. Ул вакытта Татарстанда әлеге оешмада җитештерелгән 300 мең йомырка сатудан алынды. Ул чагында республиканың бер генә авылы да куркыныч тудырган зонага эләкмәгән иде.

Татарстан Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе башлыгы урынбасары Габделхак Мотыйгуллин мондый хәлләр башка район, авылларда кабатланмасын өчен нәрсә эшләргә кирәклеген кабат искә төшерде.

– Кош-корт тотучыларга көзге айларда тагын да игътибарлырак булырга кирәк, дип гел әйтеп киләбез, – диде ул. – Хәзер барлык кошларны да ябып куярга кирәк, урамга чыгарырга ярамый. Йорт кошларын синантроп кошлардан – чыпчык, карга, чәүкә, күгәрчен, саесканнардан сакларга кирәк. Кошларның халәтен дә күзәтеп тору начар булмас. Кошларга грипп эләксә, алар үлә башлый. Әгәр алар гадәттән тыш тынычсызланса, борын тишекләреннән сыеклык акса, кикрикләре зәңгәр төскә керсә, ветеринарларга мөрәҗәгать итәргә кирәк.

Әйтеп кенә бактым

СИҢА НӘРСӘ КАЛГАН ИНДЕ?

Риман
ГЫЙЛЕМХАНОВ

Студент вакытта концертлар куеп йөрдек. Мин, концертны алып баручы буларак, халыкны эчләре катканчы көлдерергә тиеш бит инде. Репертуарымда классикларыбызның сатирик-юмористик әсәрләреннән тыш, үзебез уйлап чыгарган һәм сөйләгән саен яңа сюжетларга байый барган бер кешелек юмористик сәхнә әсәрләре дә бар иде.

Шуларның берсен – «Трамвайда» дигәнен бүген дә уйнап күрсәтә алам. Бу көннәрдә аны искә төшереп йөрдем. Һәр нәрсәдән гаеп табарга, белер-белмәс теләсә ни сөйләп, үзенең акыллы икәнен күрсәтергә тырышучы бер хатын турында иде ул. Хатын-кыз булып киенеп, бер кулыма чиләк-көянтә, икенче кулыма төенчек тотып, кешене этә-төртә трамвайга килеп керә идем дә: «Кая бара бу халык, мин инде хет катык сатып, кибетләр карап йөрим, көпә-көндез боларга нәрсә калган инде! Самай эш вакытында трамвай вагунын тутырып йөриләр шунда, оятсыз кричләр...» – дип чәрелди башлый идем.

Күптән түгел, кайда икәнен әйтмим, халык җыелган җирдә инде, бер танышым мине күрде дә бәйләнә башлады. «Халыкка дөресен әйтергә куркасыз, нәрсә генә язып ятасыз соң сез анда?» – ди. Аны Украинадагы хәлләр бик борчый икән, ә безгә, үзе әйтмешли, «Хоть бы хны», минем кебекләргә гәҗиттә нәрсә калган, янәсе. Мин аның газета-фәлән укымаганын беләм. Күрәсең, бар сәяси «гыйлем»е интернеттагы мәгълүматлар хисабына тулыланадыр.

Әле 1990 нчы елларда ук, шагыйрь һәм җәмәгать эшлеклесе Разил Вәлиев белән сөйләшеп утырганда, мин аннан Америка Президентлары администрацияләрендә югары урыннар биләгән сәясәтче Збигнев Бжезинскийның СССРны юкка чыгару буенча 25 елга план төзегән булуын ишеттем. СССРны мөстәкыйль республикаларга бүлгәләү, халыкларны бер-беренә каршы котырту, СССРны дөньяның төрле илләрендә барган сугыш-ызгышларга тарту, хәтта, төрле фильмнар күрсәтеп, СССР халыкларын рухи яктан таркату турында язылган булган ул программада. Һәм, күрәсез, Бжезинский планы өлешчә тормышка ашты иде. Моңа шактый ук дәрәҗәдә ил җитәкчеләре дә гаепле, чөнки алдын-артын уйлап бетермичә, провокацияләргә бирелделәр. Әлеге танышымның тәнкыйть сүзләреннән соң мин Бжезинский программасы, аерым алганда, «Анаконда», ягъни буар елан проекты белән тагын бер танышып чыктым һәм Бжезинский планының бүген дә яшәвенә инандым. Халык җыелган җирдә миннән көләргә теләгән танышым, әлбәттә, «Бжезинский»ның «б» хәрефен дә белми иде. Белсә, ул Американың башта СССРны, аннан Россияне юк итү планын гасырлар буе эзлекле рәвештә тормышка ашыра баруын күрми-сизми калмас иде.

Моннан берничә ел элек кенә вафат булган «хәйләкәр төлке» Збигнев Бжезинский планы буенча, бу гасырда Америка Россиягә каршы сугышырга һәм «Россия хәрабәләре өстендә» үсешкә ирешергә тиеш булган. Планда хәтта дөньяның яңача бүленеше картасы да бирелгән. Ерак Көнчыгышка – Япония, ә Төньяк Көнбатышка, Германия, Көньяк һәм Идел буена Төркия хуҗа булырга тиеш, диелгән. Америка үзенә бөтен Себерне алмакчы икән. Планда безгә каршы бетмәс-төкәнмәс санкцияләр куллану, НАТОның Көнчыгышка, ягъни Россия чикләренә якынаюы да, бу эштә Украинаны файдалану да, гомумән, Европаны Россиягә каршы котырту да каралган. Бу бит – махсус операция башланырга әллә ничә дистә еллар алдан эшләнгән план.

Миннән гаеп эзләгән танышым – сәхнә кешесе. Аның урыны – сәхнә, әмма сәяси сәхнә түгел. Шуңа күрә: «Сиңа сәясәттә нәрсә калган инде!» – диясе һәм «Трамвайда» күренешен уйнап күрсәтәсе килә. Бәлки, героинтда үзен таныр, дип әйтүем.

МАЛАЗГИРТ СУГЫШЫ,
яки Онытылган сабаклар

Рәшит
ФӘТХРАХМАНОВ

САКАЛЛЫ ФӘЛСӘФӘ

Төрекләр 26 августта Малазгирт янындагы сугышның 952 еллыгын зурлап билгеләп үтте. Юбилей да түгел инде югыйсә, әмма шанлы җиңүнең бөек нәтиҗәләрен рәсми Әнкара да, төрек гавамы да онытмый, ел саен зурлап искә ала. Эрдоган үзенең котлау нотыгында сәлҗүк төрекләренең византиялеләр гаскәрен Малазгирт янындагы җиңүе Анатолиядәге төрек хакимлегенә юл ачуын билгеләп үтте.

Беләм инде: татар укучысына Малазгирт исеме бик аз мәгълүмат бирә, күпчелеккә исә гомумән берни дә әйтми. Тарих фәннәре кандидатлары белән сөйләшеп утырганым бар: яшь галимнәр ислам дөньясының бөек җиңүләре хакында да, хурлыклы җиңелүләре турында да берни дә белмиләр диярлек. Рус тарихыннан теләсә кайсы датаны төгәл әйтеп бирергә мөмкиннәр, әмма дөнья тарихында зур роль уйнаган мөселман-христиан бил алышуларыннан торган вакыйгалар хакында күбесенчә бихәбәр. Дөресрәге, тарихны алар Россия тарихчылары шәрехләвендә кабул итә.

Әмма дә ләкин Малазгирт янындагы сугыш европалылар хәтереннән дә җуелмаган. Көнбатышлыларга аның сабаклары берничә гасырга җитәрлек ачы тәҗрибә бирә, күп кенә корольләр сугышка дәртләнеп гаскәр җыя башлагач, император Роман IV Диогенның язмышын искә төшерә дә кылычларын кире кынына тыя куялар. Танылган мөселман полководецы Алып (Алп) Арслан укыткан сабак күп еллардан соң да тәре походларының башланып китүен артка чигерә. Малазгирт янындагы сугыш исә төрекләр өчен генә түгел, бөтен ислам дөньясы өчен һәм, арттырып әйтү түгел, бөтендөнья тарихы өчен хәлиткеч әһәмияткә ия. Европа тарихчылары ул сугышны онытмадылар әле, һәм мин уйлыйм: Көнбатыш лицей-университетларында әле дә мөселман-христиан цивилизацияләренең гасырлар буена барган бәрелешләре турында сөйләгәндә, югарыда искә алынган канкоешка махсус туктала торганнардыр. Европаның сәяси элиталары да алардан хәбәрдарлардыр.

Бу юллар язылмас та иде, әмма Россия – Украина конфликты төгәлләнгәннән соң (ул кайчан булса да бер төгәлләнәчәк бит инде), Якын Көнчыгышта ислам дөньясы белән хәзерге Европа цивилизациясе арасында хәлиткеч бәрелеш көтелә. Авторны юләргә санамассыз дип уйлыйм, чөнки бәрелешкүләм зур сугышның контурлары бүген үк сызыла. Дәүләтләр ашкынып коралллана, милитарлашу чиктән ашып китте. Германия хәрби сәнәгате җитештерүне 40 процентка арттырды, диләр. Һәм бу әле чик түгел. Башка илләрдә дә хәл шул чама. Болай сугышка берниндидә сәбәп юк үзе. Сәбәп бер генә. Ул сәбәпне танылган язучы бертуган Стругацкийлар менә болайрак формалаштырганнар: «...Когда экономика в дерьмовом состоянии, лучше всего затеять войну, чтобы сразу всем заткнуть глотки». Стругацкийлар формуласының ничек эшләвен күреп торабыз бит инде.

Автор Малазгирт янындагы сугышка тукталган икән, аның сабаклары бик ачы булып ярылып ятканнан туктала. Мәйдан аз булганга күрә, сугыш алдындагы хәлне аз гына шәрехлик. Беренче тапкыр VII гасырда Хиҗазда ислам байрагы югары күтәрелгәннән соң, Византия империясе туктаусыз җирләр югалта һәм җиңелүдән җиңелүгә таба атлый. XI гасырда ислам дөньясында сәлҗүк төрекләре өстенлек итә башлый. Мөселманар, Аллаһ ризалыгы өчен сугышканда, гел җиңүгә ирешәләр, байлык өчен сугышканда, гел түбәнлеккә төшәләр. Бер нәрсәне искәртик: байлык өчен сугышканда, алар һәрвакыт диярлек үзара сугыша. Без искә алган XI гасырда сәлҗүкләр зур держава төзи. Бигрәк тә Алып Арслан хакимлек иткәндә, ул держава зур уңышларга ирешә, чөнки солтан тәкъва була һәм Аллаһ белән ике арада тыгыз

vk.com

элемтә урнаштыра. Византиялеләр мөселманнар экспансиясе нәтиҗәсендә гел позицияләрен югалтулары белән килешергә теләми. Император Роман IV, үз чоры өчен гадәттән тыш зур булган армия туплап, Кече Азиягә таба походка чыга. Берничә стратегик пунктны, шул исәптән Малазгиртны да кулга төшерә.

Алып Арслан җитәкчелегендәге гаскәрләр ул чакта бик уңайсыз хәлдә була: башка җирләрдә походлар алып бару сәбәпле, төп гаскәр аз санлы. Византиялеләр белән сугыш планга кертелмәгән. Сәлҗүкләр гаскәрен тарихчылар 30–50 меңлек, византиялеләрнекен 200 мең дип бәялиләр. Башка саннар атаучылар да бар, әмма һәркем бер нәрсәдә килешә: көчләр чагыштырмасы якынча бергә – дүрт. Алып Арслан Роман IVкә килешү тәкъдим итеп карый, әмма, килешү сәлҗүкләр башкаласында гына булачак, дигән тискәре җавап ала. Без игътибар итәргә теләгән беренче сабак та шул: килешү тәкъдим ителгәндә, кабул итү отышлырак. Гаскәр көченә ышанып тәкәбберләнергә ярамый. Башка чара калмагач, сәлҗүкләр сугыш сызыгына тезелү өчен уңайлы урын сайлый. Алар ясаган катлаулы маневрлар турында яза алмыйбыз, чөнки урын аз. Гаскәр башлыгы Алып Арыслан сугышчыларына: «Бу кырда солтан юк, мин дә сезнең белән бер сафта, солтан – Аллаһы Тәгалә генә», – дип мөрәҗәгать итә, сугышудан куркучыларга гаскәрне ташларга рөхсәт итә. Ул биргән мөмкинлекне берәү дә файдаланмый, билгеле, чөнки сугыш Аллаһ ризалыгы өчен бара, аннан баш тарту иманны югалтуга тиң. Без әйтергә теләгән икенче сабак та шул: хәрби хәрәкәтләр белән лидерлар бункерда торып түгел, фронтның алгы сызыгында торып идарә итсәләр, бик күп сугышлар башланмый калыр иде. Король Роман IV тә үз гаскәре белән була һәм сәлҗүкләргә әсирлеккә эләгә.

Тиңсез сугышта мөселманнар җиңә. Гаделлек кем ягында булса, җиңүгә шул ирешәчәк. Гаделлек бер якта да булмаса, сугыш озак бара һәм гаскәр саны һәм корал көче белән генә җиңүгә ирешелә. Әсирлеккә эләккән императорга солтан яхшы мөгамәлә күрсәтә һәм зур күләмдә алтын түләү хисабына иреккә җибәрә. Авантюралы сугыш башлаган өчен Роман IVне үз илендә каһәрлиләр: күзләрен чокып алалар һәм бернәрсәсез калдырып чыгарып җибәрәләр. Бу үлемгә хөкем итүгә тиң була. Аның бу ачы язмышы аннан соңгы императорларны берничә тапкыр мөселманнар белән бәрелеш башлаудан тыеп кала. Менә шундый гыйбрәтле җиңү ул төрекләр августта ел саен бәйрәм итә торган җиңү һәм аның сабаклары бүген аеруча мөһим. Лидерлар шул сабакларны хәтерләсә, бик күп конфликтлар башланмый калыр иде.

Илдар Мөхәммәтҗанов

АКЧА УЕНЫ

Соңгы бер айда илдә банк кертемнәре ачучылар саны биш тапкыр (!) арткан. Сәбәпләре дә билгеле. Россия Үзәк банкы 15 августта төп ставканы 12 процентка кадәр күтәргәннән соң, кредит оешмалары да финанс продуктларына процентларны арттыра башлады. Банклар күпме табыш вәгъдә итә? Бүгенге шартларда кулдагы акчаны финанс оешмасына ышанып тапшырырга ярыймы? «ВТ» хәбәрчесе нәкъ шул сорауларга җавап эзләде.

Үсә, үсә... ставка

– Маяга дигән акчаны тупланма счетта тота идек. Аның шартлары күпкә уңайлырак булса да (счеттан акчаны үзеңә кирәк вакытта алырга яки өстәргә мөмкин, процентлар да көн саен тамып тора һәм югалмый), җыелган акчабызны әле яңа гына банк кертеменә күчердек. Чөнки тупланма счетта – 6, банк кертемендә исә 12 процент еллык табыш вәгъдә итәләр. Әлегә алты айлык кертем ачтык. Югары процентлар кызыктыра бит, – дип сөйләде Казанда яшәүче Лилия Мусина.

Болай фикер йөртүчеләр шактый. Белгечләр әйтүенчә, соңгы бер айда сумлы банк кертемнәре ачучылар саны 5 тапкыр арткан. Акчаны күбрәк кыска вакытка, ягъни өч – алты айга салып куялар. Банк кертеме уртача 500 меңнән алып 1 миллион сумга кадәр тәшкил итә.

Кредит оешмаларындагы тәкъдимнәрне без дә белештек. Ак Барс банкында 12 процентлы кертем гамәлдә. Дөрес, моның өчен тиешле шартларны үтәргә кирәк. Мәсәлән, яңа клиентларга өстәмәләр бар. Унбиш елдан артык әлеге банк картасыннан файдаланган «ВТ» хәбәрчесенә 10 процентлы кертем вәгъдә иттеләр. Акчаны озаграк вакытка салган саен, процент та кими.

ВТБ банкында кертем ставкасы – 11 процент. Кредит оешмасының матбугат хезмәте мәгълүматларына караганда, августның беренче ун көнендә генә дә бирелдә 8,8 миллиард сумлык 3,5 меңнән артык кертем ачканнар инде. Июль азагы белән чагыштырганда, бу 1,5 тапкыр күбрәк.

Сбербанкның рәсми сайтында – 12, Тинькофф-банкта – 10, Альфа-банкта 12 процентлы кертемнәр турында мәгълүмат бар. Озын сүзнең кыскасы – бүген кредит оешмалары Үзәк банк ставкасы дәрәҗәсендә яки аннан кимрәк еллык керем вәгъдә итә. Тик һәркемгә дә түгел.

Ашыккан ашка пешмәс

Акча базарындагы вазгыять турында Татарстан Иҗтимагый палатасының финанс һәм икътисад мәсьәләләре буенча белгече **Фәнис ХӨСӘЕНОВ** белән сөйләштек.

> **Сан**
>
> Рәсми мәгълүматларга караганда, ил банклары һәм банкоматларындагы «тере» акча күләме тәүге тапкыр 2 триллион сумлык чикне узган. Ел башыннан бирле әлеге күрсәткеч 24 процентка үскән. Татарстанда яшәүчеләрнең банкта 829 миллиард сум акчасы саклана. Алдагы ел белән чагыштырганда, бу 20 процентка күбрәк. Кредит оешмасындагы маяның 90 проценты сумлы кертемнәргә туры килә.

:: Процент ставкалары ни өчен үсте?

– Азык-төлек бәяләре Үзәк банк фаразлаганнан да тизрәк үсә башлады. Шуңа күрә Үзәк банк төп ставканы чираттан тыш күтәрергә мәҗбүр булды. Шул рәвешле берьюлы ике максатка ирешергә телиләр. Беренчедән, куллану кредиты алучылар санын киметү күздә тотыла. Чөнки кибеттән товарны бурычка сатып алучылар саны артты. Ә төп ставка күтәрелгәч, кредит ставкасы да үсә. Икенчедән, төп ставка артыннан кертемнәр буенча процентлар да арта. Аңлашыла ки, алар кызыклырак була башлый. Димәк, халык арасында да акчасын кибеттә туздырганчы, аны банк кертеменә салып куярга теләүчеләр саны күбәячәк.

:: Кайсы отышлырак: тупланма счетмы әллә банк кертемеме?

– Иң беренче чиратта, банк ставкасы күтәрелүнең вакытлыча гына күренеш икәнен аңларга кирәк. Ул ел ахырына кадәр үк кире төшә башлаячак, дип фаразлыйбыз. Шуңа күрә кем дә булса, бүгенге ставкаларга кызыгып, банк кертеме ачарга тели икән, моны кичекмәстән эшләргә кирәк. Аны кыска вакытка, ягъни өч – алты айга ачу хәерлерәк. Мондый кертемнәр буенча процентлар да югарырак. Чөнки банклар да Үзәк банкның якын киләчәктә үк төп ставканы кире төшерә башларга мөмкин икәнен аңлый. Бу ни өчен шулай соң? Төп ставканы күтәрү без куллана торган азык-төлек бәясенең үсүен тоткарлауга китерә. Ул икътисадның үсешенә дә тәэсир итә. Чөнки төп ставка үскәч, бизнес өчен кредит ставкалары да югары сикерә. Шуңа күрә иртәме-соңмы төп ставка кире төшә башлаячак.

:: Банкка акча салганда, нәрсәне истә тотарга?

– Кыска вакытка исәпләнгән кертем отышлырак. Тик банк кертемендәге акчаны вакытыннан алда кире алырга теләгән очракта процентларның «яңу»ын истән чыгармаска кирәк. Әлеге күзлектән караганда, тупланма счетның шартлары күпкә гадирәк. Акчаны теләсә кайчан алырга мөмкин. Тик бу банк өчен отышсыз. Акчаны теләсә кайсы вакытта кире бирергә әзер булып торырга кирәк бит. Шуңа күрә тупланма счетлар буенча процент ставкасы да түбәнрәк. Иң мөһиме – канун нигезендә 1,4 миллион сумга кадәр банк кертеме иминиятләштерелгәнне онытмагыз. Әгәр сез кредит оешмасына салырга теләгән акча моннан күбрәк икән, гомуми суммасы 1,4 миллион сумнан да артмаслык итеп, аны төрле банкларга бүләргә кирәк.

Банкларга хәләл юл

Бу атнада Россиядә хәләл акча кулланышка керә. 1 сентябрьдән илнең дүрт төбәгендә, шул исәптән Татарстанда ислам финансларын гамәлгә кертүгә бәйле тәҗрибә башлана. Хәләл акчаны бездән кала, Башкортстан, Чечня һәм Дагыстанда сынап караячаклар. Тәҗрибә ике ел дәвам итәчәк. Аннан нәрсә көткәннәре дә билгеле.

Партнерлык яки «ислам финанслары» төшенчәсе республика өчен чит-ят түгел. Бу хакта яңалык гамәлгә керү уңаеннан Татарстан Министрлар Кабинетында узган брифингта Премьер-министр урынбасары – икътисад министры Мидхәт Шаһиәхмәтов та әйтте.

– Без әлеге юнәлештә 15 елга якын эшлибез, – диде ул. – 2008 елда БДБ илләрендә тәүге тапкыр Ислам банкы белән берлектә үзара бәйләнешләр турында меморандум имзаланды. Соңрак, 2011, 2014 елларда 600 миллион доллар акча җәлеп итүгә бәйле өч килешү имзаланды. Татарстанда сукук облигацияләре чыгару, шәригать кануннары буенча чит ил финанслары җәлеп итү тәҗрибәсе бар.

Министр фикеренчә, яңа канун ислам финансларын үстерүдә мөһим адым булып тора.

– Канун нигезендә, тәҗрибә барышын күзәтүче һәм көйләүче орган буларак Россия банкы билгеләнгән. Әлеге эштә теләсә кайсы оешма катнаша ала. Бер шарт – алар тәҗрибә узучы төбәктә теркәлгән булырга тиеш. Әлеге төр хезмәтләрдән файдаланырга теләүчеләргә исә бернинди чикләү дә юк. Ислам финанслары системасын сынап карарга теләүче оешмаларны Россия банкының махсус реестрына кертәчәкләр. Бирелдә үк ислам банкингы системасында катнашучыларга бирелә торган хокуклар, тәкъдимнәр һәм дәүләт ярдәме чаралары белән дә танышырга мөмкин булачак. Мәсәлән, алга таба шәригать кануннары буенча ипотека рәсмиләштерүчеләр ана капиталыннан файдалана алачак, – дип аңлатты Мидхәт Шаһиәхмәтов.

Министр әйтүенчә, моңа кадәр кредит оешмалары тәкъдим иткән гадәти продуктлар белән чагыштырганда, ислам продуктлары кыйммәткәрәк төшә иде.

– Канун нигезендә без аларны үзара тәңгәлләштерергә тырыштык. Ислам продуктлары моңа кадәр дә тәкъдим ителде. Республикада мондый финанс оешмалары бар инде. Тик әлеге өлкәне көйләүче төгәл кануннар булмаганлыктан, ислам продуктларын тәкъдим итүчеләргә катлы-катлы юл узарга туры килде. Бу исә ахыр чиктә кулланучыга күрсәтелгән теге яки бу хезмәтнең бәясендә чагылыш тапты. Канунда болар барысы да исәпкә алынды. Тәҗрибәдә катнашучылар һәм тәкъдим ителгән продуктлар күбрәк булган саен кимчелекле урыннарны ачыкларга, алга таба аларны камилләштерергә җиңелрәк булачак. Яңа эш иң беренче чиратта әнә шуңа юнәлдерелгән, – диде министр.

Россия Дәүләт Думасы депутаты Айрат Фәррахов әйтүенчә, илнең дүрт төбәген колачлаучы тәҗрибә төп ике сорауга җавап табарга ярдәм итәргә тиеш.

– Йә әлеге системаны алга таба да кануннар ярдәмендә камилләштерүне дәвам иттерәбез, йә аны гомумән туктатабыз. Шәхсән без ислам финанслары бик кирәк дип саныйбыз. Аның икътисадка да, фәнгә дә, башка өлкәләргә дә файдасы зур булачак. Илдә ислам финанслары булырга тиеш, – диде Татарстаннан сайланган депутат.

Татарстанда тәҗрибә рәвешендәге эшнең уңышлы узачагына да шик юк.

– Диния нәзарәтендә әлеге мәсьәлә ун елдан артык күтәрелеп килә. Шушы вакыт аралыгында без кадрлар әзерләүдә дә, продуктлар эшләүдә дә, сертификация узуында да яхшы нәтиҗәләргә ирештек. Үзегез үк күреп торасыз: Татарстан хәләл акча белән эшли белә һәм ул ислам банкингы буенча тәҗрибәгә тулысынча әзер, – диде Татарстан мөфтие Камил Сәмигуллин.

Эльвира ВӘЛИЕВА әзерләде

УҢЫШ АЗРАК – ФАЙДА ЗУРРАК

Республикада бәрәңге һәм башка яшелчәләрне алуга керештеләр. Быелгы уңыш сөендерәме? Бәяләргә нинди өмет баглыйлар? Гомумән, Татарстанда яшелчәчелек белән шөгыльләнү отышлымы? «ВТ» хәбәрчесе шул хакта белеште.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Отумы, оттырумы?

Чистай районының Кызыл Ялан авылында бертуган Алмаз һәм Илгиз Сабировлар унар гектар мәйданда бәрәңге һәм кәбестә үстерә. Узган ел алар кәбестә уңышының мул булуын, тик бик арзан бәядән сатылуын әйткәннәр иде. Быел исә егетләрнең кәефләре алай ук начар түгел.

– Узган ел кәбестәне 12 гектарда үстергән идек. Уңыш шәп, тел-теш тидерә торган булмады. Якынча 600 тонна җыеп алдык. Кызганыч, күпләп сату бәясе генә бик түбән булды: 5–7 сум. Башта сатмыйча тордык та, басуда калдырып булмый бит инде дип, 5–6 сумга урнаштырып бетерергә туры килде. Бик арзан хак булды инде ул, – диде Алмаз Сабиров.

Кәбестә алу сезоны октябрьдә башлана. Әлегә бәяләр билгеле булмаса да, узган ел белән чагыштырганда, уңайрак булыр, дип өметләнә алар.

– Быел корылык булды бит, шунлыктан уңыш ул дәрәҗәдә мул булмас. Әгәр Чувашиядә дә бездәге шикелле вазгыять булса, бәяләр сынатмас, дип өметләнәбез. Кәбестә белән озак еллар шөгыльләнәбез, әмма бәрәңгене өченче ел гына утырттык әле. Анысы белән эшләү кызыклырак. Аның үзкыйммәте дә арзанрак, сорау да зуррак. Узган ел җитми дә калды, шуңа күрә быел мәйданнарын арттырдык. Берәр атналардан уңыш җыярга керешәбез, узган ел белән чагыштырганда, уңышы күпкә начаррак. Дөрес, уңыш мул булган елларда аның да бәясе 2–3 сумга төшәргә мөмкин, диләр. Ләкин андый ел әлегә безгә туры килгәне юк, шуңа күрә әйтеп булмый, – диде Алмаз.

Фермер әйтүенчә, яшелчәчелектә отуотмауны алдан планлаштырып булмый. Елның уңышлы яки уңышсыз килүенә шактый факторлар йогынты ясый.

– Яшелчәчелек, бигрәк тә кәбестә белән шөгыльләнүчеләр өчен уңыш булмау яхшырак, – ди ул. – Әгәни ел никадәрле начаррак килсә, безнең өчен шуның кадәрле отышлырак. 2021 елда уңыш начар иде, уртача алганда 1,5 кг авырлыктагы кәбестәләр үстердек. Бер килограммы 35 сум иде. Әгәни бер кәбестәне 40 сумнан артыграк бәягә саттык. 2022 елда уртача 3 килолы кәбестәләр үстердек. Килосын 5–7 сумга сатып алдылар. Димәк, бер кәбестә 18 сумга чыга. Шулай итеп, 2021 елда бер тонна яшелчә сатып, 40 мең сум табыш алган булсак, узган ел шуның кадәрледән 7 мең сум керем кергән. Әле монда юл һәм эшчеләргә бирә торган чыгымнар исәпкә алынмый, – ди Алмаз Сабиров.

«Субсидияне кыстылар»

Буа районының Аксу авылыннан Фирдүс Салаватуллин 45 гектар мәйданда кишер, бәрәңге, чөгендер үстерә. Узган ел кәбестә дә үстергән булган, тик отышлы түгел дип, быел анысын утыртмаган.

– Узган ел кәбестәне хәтта Яңа ел алдыннан да 3 сумга сатарга туры килде. Бер гектардан 60 тоннадан артык кәбестә җыйган идек югыйсә. Аннан соң, һәр нәрсәнең үз вакыты бар. Барысын да вакытында эшләп өлгерергә кирәк. Узган ел 65 гектарда үскән уңышны җыеп бетерер өчен шактый тир түгәргә туры килде, – диде ул. – Яңгырларга киткәч, бәрәңгене урнаштыру авыр булды. Иң зур мәйданны кишер алып тора – 25 гектар. Быел аны август башында җыя башлаган идек, эшләр октябрьгә кадәр дәвам итәчәк әле. Уңышы елына күрә начар түгел. Бәрәңгене 9 гектарда утырттык.

Бүгенгә суган, бәрәңгенең иртә өлгерә торган сортларын җыеп алганнар инде. Алганнар да, сатып та бетергәннәр.

– Иң җиңел сатыла торганы – бәрәңге. Аның килограммын 18 сумнан җибәрдек. Башка фермерлар да шундый ук хак куйган иде. Иң авыры – чөгендерне урнаштыру. Анысын артыгын алмыйлар. Кишер белән дә авырлыклар булганы юк. Барысы да җай белән бара. Без яшелчәләрне Казандагы балалар бакчаларына, күпләп сату базарына ташыйбыз. Башка елларда Киров өлкәсеннән дә килеп алып китәләр иде. Быел аларга җиткереп булмый, – диде Фирдүс Салаватуллин.

Билгеле булганча, Татарстанның Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы яшелчәчелек белән шөгыльләнүче барлык хуҗалыкларга да субсидия биреп килә. Узган ел игү мәйданнарын 2021 ел белән чагыштырганда 10 һәм аннан да күбрәк процентка арттырган хуҗалыклар һәр гектарга 40 мең сум күләмендә субсидия алды. Быел аның күләме шактый кимеде – 17612 сумны тәшкил итә. Фермерны бу мәсьәлә дә борчый.

– Татарстанда субсидия күләмен киметү бер дә яхшы булмады, – диде Фирдүс Салаватуллин. – Күршеләребез Чувашиядә субсидияләр бирүдә үзгәреш булмады бит. Бездә генә шактый кыскарттылар. Биргән сумма гына аз, барысына да бәя арта, субсидия булгач, аларга да акчаны иркен түли ала идек. Хәзер андый ук мөмкинлекләр юк. Аларны тотып та торасы бар бит әле.

Бәрәңгесез калмыйбыз

Республикада бәрәңгене берничә эре хуҗалык үстерә: Арчаның «Кырлай» һәм «Игенче», Алабуганың «Вятские Зори» хуҗалыклары, Минзәлә районының Дәүләтов һәм Тукай районының Минеханов фермер хуҗалыклары. Әлегә икенче икмәк 300 мең гектарга якын мәйданда казылган, уртача уңыш гектарыннан 306,5 центнер чыга.

Без шалтыратканда, Минталип Минеханов бөртекле культураларны җыеп алу эшләрен тәмамлаган иде. Инде чират бәрәңгегә җиткән. Ул 100 гектардан артык мәйданда бәрәңге, кишер һәм чөгендер үстерә.

– Быел чөгендер уңышы яхшы булачак, чөнки ул – эссегә чыдам яшелчә. Кишер, бәрәңге уңышы уртача булырга охшап тора. Әлегә аның сабаклары яшел, димәк, тагын бераз үсәргә вакыт бар әле, – диде ул. – Ничек кенә булса да, халыкка җитәрлек уңыш булачак. Аннысы өчен борчылырга сәбәп юк. Без зурзур йөк машиналары белән читкә чыгармыйча, үз халкыбызга, мәктәп, балалар бакчаларына сатарга тырышабыз. Тик елдан-ел халыкның ялкаулануы гына хафага сала. Бакчаларында бераз гына яшелчә үстерсәләр, үзләренә никадәрле файда булыр иде. Балалар, оныклар да хезмәт тәмен күреп, белеп үсәр иде. Чөнки яшь буынны хезмәт һәм дин белән генә тәрбияләп була.

> Быел көзге авыл хуҗалыгы ярминкәләре 9 сентябрьдә эшли башлаячак. Алар эре шәһәрләрдә һәр атнаның шимбәсендә 23 декабрьгә кадәр узачак. Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы хәбәр иткәнчә, биредә тәкъдим ителәчәк бәрәңге, яшелчә, ит, сөт ризыклары кибет бәяләренә карaганда арзанрак хакка сатылачак.

Чәчү мәйданнары кимрәк

Татарстан халыкны бәрәңге белән – тулысынча, ә калган яшелчәләр белән 65 процентка тәэмин итә. Республиканың Авыл хуҗалыгы министрлыгы китергән мәгълүматлар буенча, быел авыл хуҗалыгы оешмаларында 1,9 мең гектарда бәрәңге һәм башка төр яшелчәләр чәчелгән. Бу, узган ел белән чагыштырганда, 600 гектарга кимрәк.

– Яшелчә утырту мәйданнарының кимүе быелгы язның иртә килүенә һәм май башындагы суыкларның зыян салуына бәйле. Чөнки барлык хуҗалыклар да бу культураларны тиешле вакытларда утырта алмады, – дип аңлаттылар министрлыкта.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Төрле елларда бәрәңге һәм яшелчә (кәбестә, кишер, чөгендер һ.б.) уңышы:

2021 елда яшелчә – **240 мең тонна**, бәрәңге – **830 мең тонна**

2022 елда яшелчә – **217 мең тонна**, бәрәңге – **800 мең тонна**

2023 ел (планда) яшелчә – **150 мең тонна**, бәрәңге – **780–790 мең тонна**

Ихтыяҗ: республика халкына елына **330 мең тонна** яшелчә кирәк.

ХӘЕРЛЕ СӘГАТЬТӘ!

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Мәктәпләр белем бирергә әзер! Кичә Рөстәм Миңнеханов белем йортларын яңа уку елына кабул итү, яңа мәктәпләрне файдалануга тапшыру чарасында катнашты. Видеоэлемтәгә Россия мәгърифәт министры Сергей Кравцов, ВЭБ РФ. дәүләт үсеше корпорациясе рәисе Игорь Шувалов та кушылды. Рәис белдергәнчә, илкүләм һәм федераль проектлар ярдәмендә республикада 11 яңа мәктәп төзелгән. Аларның бәясе – 17 миллиард сум. Моннан тыш, 139 мәктәп, 2 спорт залы, 143 мәктәп ашханәсе яңартылган һәм җиһазландырылган.

Сүз уңаеннан, 1–18 август аралыгында районнарда мәгариф оешмаларын яңа уку елына әзерләү кысасында кабул итү комиссияләре оештырылган. Мәгариф оешмаларын капиталь ремонтлау программасы мәктәпләрнең матди-техник базасын яңарту мөмкинлеге бирә. Әлеге программаларны формалаштырганда инженерлык системаларының төзеклеген тәэмин итүгә, энергия, җылылыкны югалтуны киметүгә, янгын куркынычсызлыгы, террорчылыкка каршы һәм санитар-эпидемиологик таләпләрнең үтәлүенә зур игътибар бирелә.

Сергей Кравцов мәгариф системасын нәтиҗәле оештыру буенча Татарстанны иң алдынгы төбәкләрнең берсе дип атады.

– Без һәрвакыт Татарстанны үрнәк итеп күрсәтәбез. Мәгариф оешмалары төзү буенча республика тәҗрибәсен башка төбәкләргә дә таратасыбыз килә, – диде Сергей Кравцов.

Чарада Әлки, Биектау, Тукай, Мамадыш, Арча районнары һәм Чаллы, Казан шәһәрләрендәге яңа мәктәпләр файдалануга тапшырылды. Сүз уңаеннан, 2010–2022 елларда барлыгы 88 мәктәп төзелеп, 51 меңнән артык яңа урын булдырылган.

ЯҢА МӘКТӘПЛӘР

- Тукай районы Шилнәбаш авылында – 100 урын
- Казанның Сибгат Хәким урамында – 1224 урын
- Чаллының «Притяжение» торак комплексында – 1501 урын
- Казанның «Светлая Долина» торак комплексында – 1501 урын
- Казанның «Салават Күпере» комплексында – 1501 урын
- Казанның Гәрәев урамында – 1501 урын
- Арча районы Түбән Мәтәскә авылында – 500 урын
- Чаллының 34 нче микрорайонында – 1501 урын
- Мамадыш шәһәрендә мәктәп-бакча – 240/120 урын
- Биектау районы Коркачык авылында мәктәп-бакча – 80/20 урын
- Әлки районы Түбән Колчура авылында мәктәп-бакча – 25/25 урын

* Ел ахырына кадәр Казандагы 19 нчы гимназиягә өстәмә корпус төзеләчәк.

Сан

2023 елда федераль һәм республика бюджетыннан мәктәпләрне ремонтлауга 5,6 млрд сум акча бүлеп бирелгән.

ҮЗЕБЕЗДӘ УКЫЙСЫ КИЛӘ!

Әлмәт районының Яңа Кәшер мәктәбе инде 17 ел ремонт көтә. Августның соңгы көннәрендә мәктәпнең хәлен үзебез дә күреп кайттык.

Яңа Кәшердә 1 мең хуҗалык исәпләнә, 2,5 мең кеше яши. Яңа уку елында мәктәптә 136 бала белем алачак. Былтыргы белән чагыштырганда, укучылар саны дүрткә күбрәк. 1 нче сыйныфка 12 бала киләчәк. Шунысы сөенечле: демография күрсәткече яхшыра бара. Ә менә 50 ел элек төзелгән мәктәп ярты гасыр эчендә бер генә тапкыр да капиталь ремонт күрмәгән.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Ярылган урында – маяклар

Рамилә Әхмәдуллинаның мәктәптә ике баласы укый. Аларны мәктәпкә укырга җибәрергә курка ул. «Нинди аяныч хәлдә икәнлеген үзегез күреп торасыз бит. Яңасын төземәсәләр дә, ишелгән җирен сүтеп төзекләндерсеннәр, шартларны яхшыртсыннар иде», – диде ул, балалары өчен борчылып.

Рузана Шәфигуллинаның кызы 2 нче сыйныфка бара. Аннан да шундый ук сүзләр ишеттек: кыш көне тәрәзәдән җил ыжгырганда, уку өчен нинди шартлар турында сөйләргә була?!

Мәктәп директоры Лилия Ризатдинова әлеге вазыйфада – биш ел. Шуңа күрә вазгыятьне 35 ел урынбасар булып эшләүче Лилия Насыйбуллина яхшырак белә.

– 2006 елда диварда ярыклар күренә башлагач, ишелеп төшмәсен дип, шул елны кран белән җимереп алдылар. Хәзерге вакытта эчке яктагы диварларның ярылган урыннарына ярты ел саен махсус маяклар куябыз. Үзгәрешләр булу-булмавын кенәгәгә язып барабыз. Әллә ни куркыныч юк, – диде Лилия Насыйбуллина.

Директор Лилия Ризатдинова сүзләренә караганда, моңа кадәр сыйныфларда җылылык җитеп бетмәгән. Узган елны ике җылылык казаны урнаштырганнар. Тәрәзәләр фәкыйрь хәлдә күренсә дә, батареялар җылыта икән үзе. Узган кыш сыйныфларда әллә ни суык булмады, дип ышандырырга тырышты ул.

– Ремонтны киләсе елның февралендә башлыйбыз, дигән сүз бар. Ул вакытта мәктәптә укытып тора алабыз. Безнең ишегалдында башка бинабыз да бар әле. Анда ашханә, спорт залы урнашкан, – диде ул.

Белем йортының нигезе уйный, аны да ныгытырга кирәк, дигән сүзләрне дә ишеттек. Без килгәндә, белгечләр ярык урыннарны карап йөри иде. Мәктәп җитәкчеләре әйтүенчә, прокуратурадан да килеп киткәннәр.

Милли мәктәпне югалтмыйк!

22 ел башлангыч сыйныфларны укытучы Гөлнара Вәлиева әйтүенчә, ремонтны инде күптән көтәләр. «Шундый зур авылга яңа мәктәп төзесәләр дә була инде. Һич югы төзекләндерсеннәр иде. Балаларның күрше авыл мәктәпләренә укырга барасы килми», – ди ул.

Зөмфира Фазлыева 36 ел башлангыч сыйныф укучыларына белем бирә. Милли курчаклар тегеп, укучыларында милли горурлык хисе уятырга тырыша. Курчак театры да оештырган. Төрле бәйгеләрдә дә катнашалар икән.

Кайбер авылларда укытучылар юк. Монда исә яшь белгечләр һөнәр алгач, үз мәктәпләренә укытырга кайта. 16 педагогның яртысы диярлек – яшьләр. Укучыларның БДИ нәтиҗәләре дә яхшы. Тик биналары гына яхшырмый. «Мин 3 нче сыйныфта укыганда ук, мәктәп авария хәлендә иде. Без ремонтны укыганда ук көттек. Педагогик вузны тәмамлап, бирегә эшли башлавыма өч ел вакыт үтте инде. Мәктәп һаман төзекләндерелми», – ди математика укытучысы Айзат Садриев.

Нишләргә җыеналар?

Илшат НАСЫЙБУЛЛИН, Әлмәт башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш, элемтә, транспорт һәм юл хуҗалыгы идарәсе рәисе:

– Хәзерге вакытта киләсе елга капиталь ремонт программасына документлар туплау эшләре бара. Әмма әлеге мәктәп ул исемлектә юк. Киләсе елда ремонт булыр дип кистереп әйтә алмыйбыз. «Яше утыз елдан арткан мәктәпләр» программасына кертә алмадык. Яңа Кәшер мәктәбе буенча ГИСУдан барлык кирәкле документларны сораттык. Барысы да әзер. Хәзерге вакытта җавап көтәбез.

Сиринә ҖИҺАНШИНА, Әлмәт мәгариф идарәсе башлыгының милли мәгариф өчен җаваплы урынбасары:

– Милли мәктәпнең киләчәге бар. Ремонт эшләре этаплап үткәрелеп бара. Киләсе елда тулы күләмдә башкарылыр, балаларга белем, тәрбия бирү өчен барлык шартлар да тудырылыр, дип ышанып каласы килә.

Сәрия МИФТАХОВА

4 сентябрь | Дүшәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 Утренняя программа «Здравствуйте!» 16+
09.00, 17.00 «ҖЫЛЫ ЭЗЛИ ҖАННАР». Телесериал 16+
10.00, 23.00 «ТАНКИ ГРЯЗИ НЕ БОЯТСЯ». Телесериал (субтитрлы) 12+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
11.30 «Заман көзгесе» 6+
12.00, 22.10 «АННА ГЕРМАН». Телесериал (татар телендә) 16+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә». «Акыл батл» 0+
16.00 «Гаилә учагы» 16+
16.30 «Болгар радиосы» концерты 16+
18.00, 00.50 «Таяну ноктасы» 16+
19.00 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Ак барс» – «Трактор». Прямая трансляция 6+
22.00 «Вызов 112» 16+
00.00 «Соотечественники». Магуба Сыртланова. Вырваться из лучей вражеских прожекторов 16+
00.25 «Каравай» 6+
01.15 «Кичке аш» 16+
02.05 «Манзара» 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлар белән) 16+
04.45 «Точка опоры» 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.00 «Манзара» 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 18.20, 23.10, 04.20 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней» 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Туган җир» 12+
12.05 «Йөрәктән – йөрәккә». Татарстанның атказанган артисты Гөлдания Хәйруллина турында телеочерк 16+
15.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
16.30 «Адымнар» 16+
17.00 «Музыкаль мәйдан» 16+
17.30 «Яшьләр тукталышы» 6+
19.10, 22.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
19.30 «Калеб» 6+
20.00 «Заман көзгесе» 6+
20.30, 02.35 «Таяну ноктасы» 16+
21.25 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
00.15 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
00.40 «Ватандашлар» 16+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.25 «Йөрәктән – йөрәккә». Татарстанның атказанган артисты Г. Хәйруллина турында телеочерк 16+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш…» (субтитрлы) 16+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Премьера. «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское/Женское» 16+
17.00 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.30 Информационный канал 16+
19.55 Премьера. «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «УГРЮМ-РЕКА». Многосерийный фильм (S) 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «АстроУмные» 16+
00.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Письма» 16+
01.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Мелодии моей жизни» 16+
02.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Пусть не говорят, пусть читают» 16+
02.35 ПОДКАСТ.ЛАБ «Неформат» 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Неформат» 16+
03.15 ПОДКАСТ.ЛАБ «Легкие деньги» 16+
03.50 ПОДКАСТ.ЛАБ «Обязательно к прочтению» 16+
04.30 ПОДКАСТ.ЛАБ «Антропология» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 Премьера. «Наши» 12+
16.30 «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Карина Андоленко, Роман Маякин, Александр Голубев, Мария Порошина, Лариса Удовиченко. «СПАССКАЯ. НОВЫЕ СЕРИИ» 16+
23.30 Праздничный концерт к 80-летию освобождения Луганска от фашистских захватчиков
01.00 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
03.00 «Освобождение» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 «Звёзды без правил» 12+
06.30 «Всё о главном» 12+
07.00, 10.10 Новости.
07.05, 13.25, 18.55, 21.45, 00.30 Все на Матч! Прямой эфир.
10.15 Специальный репортаж 12+
10.35 «Лучшие из лучших» 12+
11.05 Смешанные единоборства. UFC. Сирил Ган против Сергея Спивака. Трансляция из Франции 16+
12.25, 03.00 Футбол. МИР Российская Премьер-Лига. Обзор тура 6+
13.55 Футбол. FONBET Кубок России. «Динамо» (Киров) – «2Drots» (Москва). Прямая трансляция из Мурманска
16.00 «Громко». Прямой эфир
16.55 Футбол. МЕЛБЕТ-Первая Лига. «Тюмень» – «Арсенал» (Тула). Прямая трансляция
19.15 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. «Ак барс» (Казань) – «Трактор» (Челябинск). Прямая трансляция
22.30 Дартс. Профессиональная лига. Про Тур 6. Прямая трансляция из Москвы
01.25 «География спорта. Волгоград» 12+
01.55 Спортивная гимнастика. Кубок России. Трансляция из Сочи 6+
02.55 Новости 0+
04.00 Регби. PARI Кубок России. 1/2 финала. «Локомотив-Пенза» – «Красный Яр» (Красноярск) 12+

НТВ

04.50 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 «ПЁС» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.50 «За гранью» 16+
17.55 «ДНК» 16+
20.00 Премьера. «ЗАПОВЕДНЫЙ СПЕЦНАЗ» (S) 16+
22.10, 00.00 Иван Колесников, Сергей Жарков в детективе «ПЕРВЫЙ ОТДЕЛ» (S) 16+
00.45 Боевик «БРАТАНЫ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
06.40 «По делам несовершеннолетних» 16+
07.35 «Давай разведёмся!» 16+
08.35 «Тест на отцовство» 16+
10.45 «Понять. Простить» 16+
11.50 «Порча». «Поскребыш». «Побег» 16+
13.00 «Знахарка» 16+
13.35 «Верну любимого» 16+
14.10 «Голоса ушедших душ» 16+
14.45 «Кризисный центр» 16+
19.00 «Я ЗАБЕРУ ТВОЮ ЛЮБОВЬ» 16+
23.15 «Понять. Простить» 16+
00.20 «Порча» 16+
01.15 «Знахарка» 16+
01.40 «Верну любимого» 16+
02.10 «Голоса ушедших душ» 16+
02.35 «ЕДИНСТВЕННЫЙ МОЙ ГРЕХ» 16+
05.50 «6 кадров» 16+
06.00 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.20 «СМЕРШ. ЛЕГЕНДА ДЛЯ ПРЕДАТЕЛЯ». Телесериал. 3-я и 4-я серии 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
11.00, 01.40 «БЛОКАДА». Телесериал 12+
13.25, 18.50 «Специальный репортаж» 16+
13.40 «По горячим следам» 16+
14.00, 15.05, 17.15 «ЛЕТО ВОЛКОВ». Телесериал. 1-я – 3-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.00 «Оборона Ленинграда». Документальный сериал. «Сухопутный фронт». Премьера! 16+
19.55 «По горячим следам» 16+
20.10 «Загадки века». «Американские бункеры Судного дня» 12+
22.45 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.15 «Двенадцать кремлей России». Документальный сериал 12+
23.45 «ЛЕТЯТ ЖУРАВЛИ» 12+
03.30 «Легендарные самолеты» 16+
04.10 «ЛЕТО ВОЛКОВ». Телесериал. 1-я и 2-я серии 16+

5 сентябрь | Сишәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
09.00, 17.00 «ҖЫЛЫ ЭЗЛИ ҖАННАР». Телесериал 16+
10.00, 23.00 «ТАНКИ ГРЯЗИ НЕ БОЯТСЯ». Телесериал (субтитрлы) 12+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 16+
11.15 «Память сердца» 16+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «АННА ГЕРМАН». Телесериал (татар телендә) 16+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Юлчы» 16+
14.00 «Путь» 16+
14.15 «Не от мира сего…» 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Төймә» 0+
16.00 «Ватандашлар» 16+
18.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
21.00 «Соотечественники» 16+
00.00 «Видеоспорт» 16+
00.25 «Каравай». Мастер – изготовитель тальянок 6+
00.50 «Соотечественники». Лилиана Терегулова. Делай добро и бросай в воду 16+
01.15 «Кичке аш» 16+
02.05 «Манзара» 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлар белән) 16+
04.45 «Точка опоры» 16+
05.35 «Оныта алмыйм…» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 18.20, 23.10, 04.20 «Җырлыйк әле!» 12+
09.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
10.30 «Заман көзгесе» 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Нәсыйхәт» 16+
12.05, 21.25 «Ком сәгате» 16+
15.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
16.30 «Таяну ноктасы» 16+
17.00 «Музыкаль мәйдан» 16+
17.30, 19.35 00.40 «Татарлар» 12+
19.10, 22.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
20.00 «Халкым минем» 12+
20.30, 02.40 «Таяну ноктасы» 16+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
03.05 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.30 «Йөрәктән – йөрәккә». Ркаил Зәйдулла турында телеочерк 16+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш…» (субтитрлы) 16+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Премьера. «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское/Женское» 16+
17.00 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.30 Информационный канал 16+
19.55 Премьера. «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «УГРЮМ-РЕКА». Многосерийный фильм (S) 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 К 90-летию Эрика Булатова. «Живу и вижу» 16+
01.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Креативные индустрии» 16+
01.35 ПОДКАСТ.ЛАБ «20 лет спустя» 16+
02.10 ПОДКАСТ.ЛАБ «Жизнь замечательных» 16+
02.50 ПОДКАСТ.ЛАБ «Мелодии моей жизни» 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Мелодии моей жизни» 16+
03.30 ПОДКАСТ.ЛАБ «Анекдоты» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 Премьера. «Наши» 12+
16.30 «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Карина Андоленко, Роман Маякин, Александр Голубев, Мария Порошина, Лариса Удовиченко, Михаил Жигалов, Дмитрий Ульянов, Анастасия Стоцкая, Никита Тезин. «СПАССКАЯ. НОВЫЕ СЕРИИ» 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 12+
03.45 «СЕМЕЙНЫЙ ДЕТЕКТИВ» 12+

МАТЧ ТВ

06.00, 15.25 «Звёзды без правил» 12+
06.30 «Наши иностранцы» 12+
07.00, 10.10, 15.00 Новости.
07.05, 15.55, 18.45, 21.45, 00.30 Все на Матч! Прямой эфир
10.15, 15.05 Специальный репортаж 12+
10.35 «Лучшие из лучших» 12+
11.35 Баскетбол. Чемпионат мира. Мужчины. 1/4 финала. Прямая трансляция из Филиппин
13.40 «Есть тема!» Прямой эфир
16.25 Хоккей. OLIMPBET Чемпионат МХЛ. МХК «Спартак» (Москва) – «Академия Михайлова» (Тульская область). Прямая трансляция
19.15 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. ЦСКА – «Металлург» (Магнитогорск). Прямая трансляция
22.30 Дартс. Профессиональная лига. Про Тур 6. Прямая трансляция из Москвы
01.25 «География спорта. Камчатка» 12+
01.55 Спортивная гимнастика. Кубок России. Трансляция из Сочи 6+
02.55 Новости 0+
03.00 Хоккей на траве. Кубок наций. Финал. Трансляция из Казани 6+
04.00 Регби. PARI Кубок России. 1/2 финала. «Стрела» (Казань) – «Динамо» (Москва) 12+

НТВ

04.45 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Остросюжетный сериал «ПЁС» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.50 «За гранью» 16+
17.55 «ДНК» 16+
20.00 Премьера. Остросюжетный сериал «ЗАПОВЕДНЫЙ СПЕЦНАЗ» (S) 16+
22.10, 00.00 Детектив «ПЕРВЫЙ ОТДЕЛ» (S) 16+
00.45 Боевик «БРАТАНЫ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
07.45 «Давай разведёмся!» 16+
08.45 «Тест на отцовство» 16+
10.55 «Понять. Простить» 16+
12.00 «Порча». «Младшая сестра». «Труба» 16+
13.05 «Знахарка» 16+
13.40 «Верну любимого» 16+
14.15 «Голоса ушедших душ» 16+
14.50 «Кризисный центр» 16+
19.00 «ЯБЛОКО РАЗДОРА» 16+
23.15 «Понять. Простить» 16+
00.20 «Порча» 16+
01.15 «Знахарка» 16+
01.40 «Верну любимого» 16+
02.10 «Голоса ушедших душ» 16+
02.35 «КАРНАВАЛ» 16+
05.00 «6 кадров» 16+
05.50 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.55 «ЛЕТО ВОЛКОВ». Телесериал. 3-я серия 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
11.00, 01.35 «БЛОКАДА». Телесериал 12+
13.25, 18.50 «Специальный репортаж» 16+
13.40 «По горячим следам» 16+
14.00, 15.05, 17.15 «ЛЕТО ВОЛКОВ». Телесериал. 4-я – 6-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.00 «Оборона Ленинграда». Документальный сериал. «Морской фронт». Премьера! 16+
19.55 «По горячим следам» 16+
20.10 «Улика из прошлого». «Мины при плохой игре. Сверхприбыль на кассетных боеприпасах» 16+
22.45 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.15 «Двенадцать кремлей России». Документальный сериал. Премьера! 12+
23.45 «ЖАВОРОНОК» 12+
02.50 «Герой 115». Документальный фильм 16+
04.10 «ЛЕТО ВОЛКОВ». Телесериал. 4-я и 5-я серии 16+

КОТЛЫЙБЫЗ!

Дәүләтнең мөһим бурычларын хәл кылуга үзләреннән зур өлеш кертүләре һәм күп еллар буе намус белән эшләүләре өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары **Камалтынов** Юрий Зимелевич, Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары **Нигъмәтуллин** Рөстәм Камил улы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **Почет ордены** белән бүләкләнделәр.

* * *

Хезмәттәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен «Татнефтехиминвест-холдинг» акционер җәмгыяте генераль директоры **Яруллин** Рафинат Самат улы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **Почет ордены** белән бүләкләнде.

* * *

Фәнни-педагогик эшчәнлегендәге, квалификацияле белгечләр әзерләүдәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе Фундаменталь медицина һәм биология институты Югары медицина мәктәбе Медицина һәм формация үзәгенең кафедра мөдире **Хафизов** Рәис Габбас улына Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Россия Федерациясенең атказанган табибы»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Нефть һәм газ сәнәгате өлкәсендәге казанышлары, күп еллар буе намус белән эшләве өчен В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыяте генераль директоры киңәшчесе **Исмәгыйлев** Фәнзат Җәүдәт улына Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Россия Федерациясенең атказанган нефть һәм газ сәнәгате хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Авыл хуҗалыгы өлкәсендәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен «Сөләйманов Әхтәм Исмәгыйль улы» крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы урынбасары **Хәйдәрҗанов** Ирек Салихҗан улына Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Россия Федерациясенең атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Мәгариф өлкәсендәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен «Физик мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Мәчкәрә интернат-мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры **Сабитов** Шәүкәт Нәкыйп улына Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Россия Федерациясенең атказанган укытучысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Икътисад һәм финанс өлкәсендәге казанышлары, күп еллар буе намус белән эшләве өчен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) каршындагы Эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил – Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе **Абдулганиев** Фәрит Солтан улына Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Россия Федерациясенең атказанган икътисадчысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Эшендә зур уңышларга ирешүе, күпьеллык намуслы хезмәте һәм актив иҗтимагый эшчәнлеге өчен «Түбән Кама нефть базасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте киңәшчесе **Метшин** Айрат Рәис улы **«Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

* * *

Һөнәри эшчәнлектәге казанышлары һәм дәүләт хакимияте органнарында күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Рәисе референты **Галиәхмәтов** Альберт Фердинант улы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

* * *

«Алабуга-2. Нефть химиясе» идарәче компаниясе җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Гайфуллин** Рамил Айрат улына **«Татарстан Республикасының атказанган нефтьчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Идел-Кама төбәкара идарәсе җитәкчесе **Шакиров** Фаяз Фәнил улына **«Татарстан Республикасының атказанган экологы»** дигән мактаулы исем бирелде.

ЯШЕРЕН ДОШМАН

Җир шарында яшәүчеләрнең өчтән бере бөер авыруларыннан интегә. Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы белгечләре шулай дип ышандыра. Организмыбызны даими рәвештә чистартып торучы иң мөһим органнарның берсе ул. Аны ничек сакларга? БАДлар ярдәмендә бөер чистарту дөресме?

Табиб-нефролог Ильмира ГАЛИНА бөергә бәйле сорауларыбызга ачыклык кертте.

:: Бөер авырулары бүген ни дәрәҗәдә киң таралган?

– Бүген Җир шарында яшәүчеләрнең 15 проценты хроник бөер авыруларыннан интегә. Кызганыч, бу сан елдан-ел арта бара. Үлем-китем, инвалидлыкка китергән иң мәкерле чирләрнең берсе санала ул. Соңгы арада бөер ялкынсыну (пиелонефрит), бөергә таш утыру, шикәр чире яки кан басымы күтәрелү аркасында пәйда булган хроник бөер авырулары бигрәк тә еш очрый. Бөер ялкынсынудан күбесенчә яшь кызлар интегә. Бу аңлашыла да: матурлык артыннан куып, күп кенә гүзәл затлар сәламәтлеге турында оныта, туңса да, түзә. Бу исә, үз чиратында, күп кенә мөһим органнарның, шул исәптән бөернең ялкынсынуына китерә. Бөергә таш утыру очраклары исә дөрес тукланмаган, сәламәт яшәү рәвеше алып бармаган кешеләр арасында күбрәк очрый. Ул нәселдән дә күчәргә мөмкин.

:: Бөер авырулары үзләрен нинди билгеләр буенча сиздерә?

– Бөердә хилафлыклар булганда, иң беренче чиратта, бил авырта. Андый чакта кичекмәстән терапевт, невролог, нефрологка мөрәҗәгать итәргә кирәк. Төнлә кече йомыш белән еш йөрергә туры килсә дә, шикләнергә җирлек бар. Норма буенча кеше төнлә, гомумән, кече йомыш белән йөрергә тиеш түгел. Кан басымы әледән-әле күтәрелеп, аны дарулар ярдәмендә генә рәтләп булмаса да, бөерләрне тикшертергә кирәк. Куллар, аяклар шешенсә, хәлсезлек борчыса, кеше тиз арыса, аппетиты югалса да, табибка мөрәҗәгать итәргә кирәк.

:: Алар бернинди билгеләрсез генә дә уза аламы?

– Әйе, бөер авырулары үзләрен бернигек сиздермичә, яшерен рәвештә дә уза ала. Шуңа күрә аларны еш кына «яшерен үтерүче» дип тә йөртәләр. Гомумән, бөер авыруларының күбесе бернинди билгеләрсез уза. Ник дигәндә, аларда авырту рецепторлары булмый. Авырту фәкать чир шактый аза башлагач – бөер тукымалары тартылганда (гидронефроз, поликистоз), бөергә таш утырганда, анда шеш пәйда булганда гына борчый башлый.

:: Соңгы арада бөерләрне үзлегеннән төрле БАДлар, үлән чәйләре ярдәмендә чистартучылар күбәеп китте...

– Бөерләрне үзлегеңнән генә дәваларга маташу – зур хата. БАД ахыргача өйрәнелеп, дәлилләнеп бетмәгән препарат санала. Шуңа күрә эчкән очракта да аны дәвалану өчен түгел, ә сәламәтлек белән бар да тәртиптә булганда, профилактика өчен генә эчәргә ярый. Берара Кытайда җитештерелгәнябыктыра торган чәйләр популярлашып алган иде. Озак та үтми, аны эчкән гүзәл затлар бер-бер артлы хастаханәгә эләгә башлады. Алар, нигездә, хәлсезлектән, бил авыртудан зарланды. Тикшерә торгач, ябыктыра торган чәйләр аркасында бөерләренә зыян килгәнлеге ачыкланды. Ник дигәндә, андый чәйләрнең составында бөергә «бәрә» торган аристохолий кислотасы бар. Бөерне чистартырга уйлаган кеше нарат җиләге, мүк җиләге, гөлҗимеш чәе эчә ала. Алар ялкынсынудан саклый, сидек кудыра.

pinterest.com

БӨЕРЛӘР СӘЛАМӘТ БУЛСЫН ӨЧЕН



✓Даими рәвештә табибка күренеп торырга, профилактик медицина тикшеренүләренә җаваплы карарга кирәк.
✓Көненә 2 литр чиста су эчү, сәламәт яшәү рәвеше алып бару да мөһим.
✓Артык майлы, ачы, тозлы ризык – бөерләрнең дошманы. Моны һәрчак истә тотыгыз.
✓Кан басымын, кандагы глюкоза, холестерин күләмен дә һәрчак контрольдә тотыгыз.

:: Кahвә эчәргә яратучыларга ни дисез?

– Кahвәнең бөерләргә бер зыяны да юк. Дөньякүләм нефролог, кардиолог, терапевтлар тарафыннан күптән расланган бу. Дөрес, чама хисен дә онытырга ярамый. Организмга зыян булмасын өчен көнгә күп дигәндә 4 чынаяк кына кahвә эчәргә рөхсәт ителә. Башка эчемлекләргә килгәндә, яшел чәй бөерләр өчен файдалырак санала. Ә менә исерткеч эчемлекләр бөерләргә зур зыян сала. Аерым алганда, алар бөер тукымасының зарарлануына (нефропатия) китерә.

:: Бөерләргә ни сәбәпле таш утыра?

– Подагра авыруыннан интеккән, чистартылмаган каты селтеле су эчкән, ачы ризык ашарга яраткан кешедә еш күзәтелә ул. Сидек юллары ялкынсынганда, организмга Д, А витамины җитмәгәндә, остеопороз вакытында да бөерләргә таш утырырга мөмкин. Бу күренеш нәселдән дә күчә ала. Ташларны алдырмасаң, кан китәргә, түзеп булмаслык көчле авырту башланырга, ахыр чиктә, бөтенләй бөерсез үк калырга мөмкин.

Күзге бакчаның күрке – кабак

Табигать шифаханәсе

Аның составында күз күрүен яхшыртучы каротиноид күп. Кабак кан басымын төшерә, эчәклекләрне шлаклардан чистарта, йокысызлыктан интеккән кешеләргә дә файдалы. Халык медицинасында кабакны бавырны чистарту өчен кулланалар. Кабак төше ир-атларга аеруча файдалы. Ул мәни безе эшчәнлеген җайга сала. Картаюны да тоткарлый. Тырнак һәм чәчләрне витаминнар белән баета.

Кайбер кешеләрдә кабакка аллергия күзәтелергә мөмкин. Кабак төше майлы, туклыклы булып санала, шуңа күрә ябыгырга теләгән кешегә аны ашарга киңәш ителми. Гастрит, ашказанында җәрәхәт булганнарга да аны саклык белән генә ашарга кирәк.

БӨЕРЛӘРНЕ ЧИСТАРТУ ӨЧЕН

Дөрес эчкән очракта, кабак суының бөерләрдән вак ташларны һәм комны чыгаруы фәнни яктан дәлилләнгән. Кабак суы ялкынсынуны кимәтә, сусауны баса, тынычландыра, бәвел кудыра.

СУАЛЧАННАРНЫ БЕТЕРҮ ӨЧЕН

Киптереп чистартылган 300 г кабак төшен яхшылап изегез, бал яисә кайнатма өстәгез. Бу катнашманы акрын гына (1 сәгать дәвамында) ач карынга ашагыз. Аннары тозлы эчйомшарткыч су эчегез һәм ярты сәгатьтән туры эчәкка сыеклык кертегез.

ҮТ КУЫГЫ ЯЛКЫНСЫНГАН ВАКЫТТА

Үт куыгы һәм бавыр ялкынсынудан «кабак сөте» эчү файдалы. Аны әзерләү өчен 50 г чистартылган төшкә су

(80 мл) һәм шикәр комы (20 г) салып изегез. Аннары файдалы «сөт»не ач карынга эчегез. Бавырга кабак орлыклары төнәтмәсе дә файдалы. 250–500 г орлыкка 0,5–1 л кайнар су салып, 2 сәгать төнәтегез. Төнәтмәне 1 сәгать дәвамында эчәргә кирәк.

ҮТ КУДЫРУ ӨЧЕН

Кабак йомшагын турап, тары боткасы пешерегез. Боткага май, сөт, бал өстәгез. Мондый ботканы һәр көнне ашагыз. Ул үт куыгы авырулары вакытында да файдалы.

Үзем сынадым

Күзән җыерса...

Аякны күзән җыерса, бер чәй кашыгы вакланган суган кабыгына бер стакан кайнар су салып, 10 минут төнәтергә кирәк. Аны йоклар алдыннан эчсәң, төнлә аякны күзән җыерып тилмертмәс.

Казаннан Әлфинур апагыз

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Валентина СЕМЕНОВА

ЧӘЧӘК... АЮЧИКЕРТКӘНЕ КУРКЫТА

Тырнак гөл (календула), алтын чәчәк (хризантема), бәрхет гөл (бархатцы) кебек чәчәкләр җәй буе күзләребезне иркәләп, болытлы көннәрдә, гүя кояш чыккан кебек, тирә-юньгә нур сипеп торды.

Кырау төшеп, сабаклары һәм чәчәкләре каралгач, аларны мин йолкып чүплеккә ташламыйм, компостка да салмыйм. Бәлки үсенте сабакларын бәйләмгә җыеп киптерәм дә язын, яшелчә утыртканда, һәркайсының төбенә салып калдырам. Яисә көзен, көрәк белән бераз чапкалап, түтәлгә күмәм. Бу чәчәкләрнең сабагы аючикерткә, кырмыска ише корткычларны куркыта. Шул ук вакытта, яшел ашлама кебек, туфракны да баета. Чәчәкләрен исә, ваклап, теплица туфрагына чәчеп калдырырга тырышам. Туфракны зарарсызландырырга ярдәм итә алар. Суз уңаенда, тырнак гөлнең бик әйбәт сидерат булуын да әйтеп үтим. Моның өчен аны сентябрь башында чәчү әйбәт. Тишелеп чыккач, туфракның астын өскә әйләндереп чыгарга кирәк.

Бәрхет гөлгә аерым тукталып үтәсем килә. Алар җәй буе безнең бәрәңге буразналары арасында да үсеп утыра. Үсемлек колорадо коңгызына бик нык үрчергә ирек бирми шикелле. Аннан килеп, чәчәкләреннән төнәтмә ясап эчәм, помидор тозлаганда кулланам. Антисептик сыман, ул микроблардан котылырга ярдәм итә.

Шулай ук кишер, чөгендер, редис, торма кебек яшелчә сабагын да (көрәк белән бераз чапкалап) туфракка күмеп куям. Ләкин бәрәңге, помидор сабакларын, кәбестә кучәнен һәм яфракларын кызганмыйча ташлыйм. Чөнки алар төрле чир һәм корткычлар гына таратачак.

Тәнзилә КАЮМОВА.
Балтач районы

ҖЫЯР ҺӘМ УТЫРТЫР ЧАК

Көзнең беренче ае – сентябрьгә кердек. «Россельхозцентр» оешмасының Татарстан буенча филиалы җитәкчесе урынбасары Гүзәл Хөсәенова бакчачыларга бу чорның төп мәшәкатьләре турында искә төшереп үтте.

– Кыяр, помидор, борыч яки ташкабак ише җылылык яратучы яшелчә түтәлләрен төнгә каплап калдырырга онытмагыз. Чөнки аларга аз гына кыраудан да нык зыян килә. Яшелчәне яраксызга чыгару өчен бер суык төн дә җитә. Бары тик соң өлгерешле кәбестәне генә октябрьгә кадәр япмыйча торгарга мөмкин. Суз уңаеннан, җәй узгач, аңа су сибәргә кирәкми.

Фосфорлы һәм калийлы ашлама

Сентябрь – бушап калган түтәлләргә сидератлар (арыш, фацелия, горчица) чәчү өчен уңайлы чор. Алар, бик тиз үсеп, чүп үләннәрне «кысрыклый» һәм туфракның уңдырышлылыгын арттыра.

Чабып алынган үлән һәм коелган яфраклардан компост ясарга мөмкин. Ул, череп, киләсе елда туфракка кертү өчен менә дигән ашламага әйләнәчәк. Ләкин черегән алма һәм җимеш агачлары-куаклары яфракларын компост өчен файдаланмау хәерле. Ник дигәндә, алар авыру чыганакларына, корткычларның кышлау урынына әйләнергә мөмкин.

Көзен агач-куаклар төбенә фосфор һәм калийлы ашлама кертү әйбәт. Алар агачларга җиңелрәк кышлау һәм язын әйбәт үсеп китү, чирләрдән котылу, мулрак җимеш бирү өчен кирәкле матдәләр туплау мөмкинлеге бирәчәк. Ә менә азотлы ашлама кулланырга ярамый, чөнки агачның кирәкмәгән үсентеләр җибәрүенә генә китерәчәк.

Утырту вакыты

Сарымсакны кышка сентябрьнең икенче яртысы – октябрь башларында, ә суганны бераз соңрак – октябрь урталарында утыртабыз. Иң мөһиме – суыкларга кадәр алар тамыр җибәреп калырга тиеш.

Сентябрь аенда агач-куакларда бер генә җимеш тә калмасын. Юкса корткыч һәм авыру чыганагына әйләнәчәкләр. Черегән алмаларны агач төбендә калдырырга яки киртә аша чокырга ташларга да ярамый. Агач ботакларында эленеп калган алма нинди зыян китерсә, болары да нәкъ шулай булачак.

Бу ай җиләк куакларын (мәсәлән, карлыганы) ботактан үрчетә башлау – ботакны тамырландыру өчен бик уңайлы чор. Шулай ук куакларның корыган-сынган ботакларын кисәргә онытмагыз.

Игътибар! Корткычлардан котылу өчен җимеш агачлары һәм куаклары-на, яфраклары коела башлаган чорда, Ризоплан, Фитоспорин, Псевдобактерин-2 кебек биофунгицид өстәп, 5 процентлы мочевина эремәсе бөркергә кирәк. Ә инде яфраклары коелгач – 3 процентлы тимер купоросы эремәсе яки 3 процентлы бордос сыекчасы белән эшкәртергә.

Кызыл булсын дисәң

Чөгендер ашы кып-кызыл булып пешсен өчен ризыкны башыннан алып ахырына кадәр көчле утта пешерергә кирәк. Ташымасын өчен суын кәстрүлгә яртылаш кына салырга. Ә инде ахырда шулпага кәстрүлне тутырып кайнар су өстәргә. Болай эшләгәндә, борщның төсе дә матур һәм бик тәмле дә булачак.

Кышка әзерлек

Абхазча аджика

НУРАНИЯ КЫЯМОВА ЫСУЛЫ

Аджика бик әче, уртача әчелектә һәм җиңелчә генә әче булырга мөмкин. Әче борычның күләменә бәйле бу. Без уртача әчелектәге аджиканы сайлап аласы иттек.

Кирәк: 500 г әче кызыл борыч (орлыклары белән), 500 г татлы кызыл борыч, 250 г сарымсак, 100әр г яшел тәмләткечләр (базилик, укроп, петрушка, кинза, сельдерей), үсемлек мае, 1,5 аш кашыгы тоз, тәменчә төелгән кара борыч, хмели-сунели, кориандр орлыклары.

Әче һәм татлы борычның барысын да сарымсак, яшел тәмләткечләр белән бергә иттарткыч аша чыгарабыз. Катнашмага тәменчә тоз, төелгән борыч, хмели-сунели өстибез. Барысын бергә

болгатып, өч көнгә салкынча урынга куябыз (әмма суыткычка түгел). Әледән-әле болгатып торабыз.

Аджиканы өч көннән кечерәк банкаларга (парландырылган) тутырабыз. Һәр банкага 1әр чәй кашыгы кайнар үсемлек мае өстибез. Капкач белән ябып, салкынча урында саклыйбыз.

Белеп тор!

2 минутта пешә

Яшелчәне (бәрәңге, чөгендер, кишер) кыска дулкынлы мичтә пешерүнең гади генә бер сере бар. Әйтик, бәрәңгене, эрерәк кисәкләргә турап, мичкә куйганчы, суга чылатылган кәгазь сөлге белән өч кат төрергә кирәк. Болай эшләгәндә, 2–6 минут эчендә пешеп җитәчәк. Асылда яшелчәне парда пешерүгә охшаш ысул бу.

Чиста көзге

Көзге чистарта торган сыекча бетеп китсә, кулны чистарту өчен билгеләнгән антисептиктан файдаланырга мөмкин. Бернинди дә эз калдырмыйча, көзгене бик әйбәт чистартачак!

МУЛ УҢЫШ БЕЛӘН БҮЛЕШ

ru.freepik.com

Халык җәй буе тир түгеп үстергән уңышын акрынлап җыя башлады. Сакларга куйганчы, аннан әле гошер чыгарасы бар. Бу нәрсә өчен кирәк? Гошерне кемнәргә бирәсе?

Әлеге һәм башка сорауларга Раил хәзрәт ФӘЙЗРАХМАНОВ ачыклык кертте.

– Гошер – зәкятнең бер төре. «Бәкара» сүрәсенең 267 нче аятендә: «И иман китерүчеләр! Кәсеп итеп тапкан малларыгыздан һәм Без сезнең өчен җирдән чыгарган уңышлардан яхшысыннан сәдака бирегез», – диелә. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) бер хәдисендә: «Җыеп алынган уңышның яңгыр һәм елга сулары белән үстерелгән өлешеннән – уннан бере, ә хезмәт куеп, су ташып үстергәненнән бер өлеше сәдака итеп бирелергә тиеш», – дигән. Бодай, арпа, башка бөртекле культуралардан гошер чыгару фарыз. Кишер, чөгендер, бәрәңгедән дә бирергә ярый. Гошер – Аллаһы Тәгаләгә шөкер итеп, уңышың белән бүлешү ул.

:: Гошер сәдакасын кемнәр кемнәргә бирергә тиеш? Аны кайчанга кадәр тапшыру тиешле?

– Гошер – зәкятнең бер төре, дидек. Аллаһы Тәгалә зәкятнең кемнәргә тиешле икәнен Коръәндә әйткән. Болар – мескеннәр, фәкыйрьләр, юлда акчасыз калган, кайтырга мөмкинлеге булмаган мосафирлар, бурычка баткан кешеләр, Аллаһы Тәгалә юлындагылар. Уңышны алгач та, сузмыйча, гошер тапшыру хәерле.

:: Гошерне теләсә кайсы яшелчә, җиләк-җимештән бирергә ярыймы?

– Әлбәттә, сәдаканы, изгелек йөзеннән, алмадан да, кыярдан да бирергә мөмкин. Әмма зәкят саналсын өчен, бозылмый торган, озак вакыт саклана торган культуралардан бирү фарыз. Сәдаканың, һичшиксез, әҗере булыр.

:: Кайнатма, бал, консервланган банкалар, пирог, салат, сок, компот рәвешендә бирергә рөхсәт ителәме?

– Алар да сәдака булып санала. Балга килгәндә, аны да гошер итеп, уннан бер өлешен бирергә була.

:: Гошер сәдакасын тапшырганда аерым дога укыламы, яисә нәрсә әйтеп бирү хәерле?

– Аерым догасы юк. Ихласлык кирәк. «Йә, Раббым, биргән уңышың өчен рәхмәт», – дип теләп, ниятләп бирсәк, дөрес булачак.

:: Корылык булып, уңышка зыян килеп, ул аз булган очракта, гошер бирмәү рөхсәт ителәме?

– Корылыкка, уңышның аз булуына безнең гөнаһлар, Аллаһтан ерагаю сәбәпче. Бутән ел 100 капчык бәрәңге алып, быел 10 гына булса, шуңа да карамастан, гошер биреп: «Йә, Раббым! 10 капчык булса да, булды бит әле», – дип, шөкер итеп, ихлас ният белән гамәл кылсак, Аллаһы Тәгалә калган 9 капчыкны да ел буена җитәрлек итәргә мөмкин. Аллаһы Тәгалә бәрәкәт бирә. Сәдака малны киметми, ә арттыра. Юмартлык саранлыкка караганда хәерлерәк. Без җитмәс дип уйлыйбыз, ә юмартлык, киресенчә, яшәтәчәк, малны арттырачак.

Хикмәтле сүз

«Аллаһы кемне дә булса [туры юлга] һидаять итәргә теләсә, Ул аның күкрәген ислам өчен ачар. Әмма кемне дә булса [туры] юлдан яздырырга теләсә, аның күкрәген кысар һәм [эченә иман нуры керә алмаслык итеп] тарайтыр [шул сәбәпле, исламга чакырылган чагында] гүяки, ул [авырлык белән, сулый алмыйча] күккә менә».

«Әл-Әнгам / Терлек», 6:125

Явызлык анасы

Гыйбрәт ал!

Беркем өчен дә сер түгел: исерткеч эчемлекләр кешенең тәненә дә, аңы белән җанына да, ягъни физик һәм рухи сәламәтлегенә бик зур зыян китерә. Әгәр: «Аракы эчүдән бәхетле булган кешене күрсәтегез әле», – дип сорасак, андый кешене күрсәтүче табылмаячак. Әмма: «Аракы эчүдән күп зыян күргән һәм бәхетсез булган кешене күргәнегез бармы?» – дигән сорауга күпләр уңай җавап бирер, бик күп мисаллар китерә алачак. Дөрестән дә, шушы зәхмәт аркасында күпме кеше әрәм булган, күпме гаилә таркалган, гарип бала туган, ничә кеше җинаять юлына баскан, исерек килеш машинага утырып, юл һәлакәтенә очраган, имгәнгән, гүр иясе булган...

pxhere.com / Фото бизәү өчен бирелде

Ислам дине буенча хәмер эчү ул – хәрам, ягъни Аллаһы Тәгалә катгый тыйган гамәл. Бу хакта «Маидә» сүрәсенең 90 нчы аятендә әйтелә: «Исертә торган эчемлекләр һәммәсе дә, отыш уеннарының һәртөрлесе дә, сыннарга гыйбадәт кылу һәм багучылык кебек нәрсәләр – хәрам, шайтан шөгыленнән булган нәҗес, шакшы эшләрдер. Шул нәрсәләрдән читләшегез, бәлки, Аллаһ газабыннан котылып, бәхеткә ирешерсез».

Кайбер кешеләр: «Чамасын белсәң, хәмернең ни зыяны бар соң?» – дип әйтә. Әмма үзенең бер хәдисендә Мөхәммәд (с.г.в.) бу хакта болай дигән: «Хәрамның азы-күбе юк». Бу нәрсә дигән сүз? Кеше нибары 10 сум урласа да, миллион үзләштерсә дә, Аллаһ каршында хәрам гамәл кылган карак була; бер кеше турында гайбәт сөйләдеңме, 100 кеше турындамы – ике очракта да гайбәтче буласың. Нәкъ шулай ук зур күләмдә исертә торган нәрсә аз күләмдә булганда да хәрам, ягъни аз гына хәмер эчү дә Аллаһ җәзасына лаек гөнаһлы гамәл булып санала.

Аллаһның соңгы илчесе пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.): «Исертә, акылны томаландыра торган эчемлекләрне «ярый» дип әйтүченең миңа һәм минем өммәтемә берни дә катнашы юк», – дип белдерде. Алай гына да түгел, хәдисләрнең берсендә хәбәр ителгәнчә, Аллаһы Тәгалә аракы эчүчене генә түгел, аны ясаучыны, төяүчене һәм бер урыннан икенче урынга күчерүчене, сатучыны, хәмер белән кәсеп итеп, шул акчага яшәүчене, сатып алучыны, салып бирүчене дә ләгънәт кыла.

Госман ибне Гаффән фикерен китерү бик урынлыдыр дип уйлыйм. Ул болай дигән: «Әй кешеләр! Хәмердән сакланыгыз, чөнки ул – барча начарлыкларның анасы!»

(Кукмара мәдрәсәсе мөдире Ришат хәзрәт Курамшинның шәхси сәхифәсеннән кыскартып алынды)

Белеп тор!

КАБЕР ГАЗАБЫ СӘБӘПЛӘРЕ

•Факыйһ радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Бер кеше кабер газабыннан котылырга теләсә, аңа дүрт төрле нәрсәне үтәү һәм дүрт нәрсәдән саклану лязем (тиеш) булыр. Тиешле булган дүрт нәрсә: намаз уку, сәдака бирү, Коръән уку, тәсбихләрне күп кылу, чөнки бу нәрсәләр каберне яктырта һәм киң кыла. Әмма кабер газабыннан саклана торган дүрт нәрсә: ялган, хыянәт, сүз йөртү һәм бәвелдер».

•Дөреслектә, пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Бәвелдән (сидектән) сакланыгыз, чөнки кабер газабының күбесе бәвелдән сакланмаганнандыр». Шулай ук пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә сезгә дүрт нәрсәне мәкруһ кылды: намазда буш эш, Коръән укыганда уйнау, уразада яман сүз сөйләү, кабер янында көлү».

•Мөхәммәд бине Сәмәктән риваять ителгән: «Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләм зиратка караган һәм: «Бу кабернең тик торуы сезне алдамасын. Ни гаҗәп, ул каберләрдә кайгылылар күп булды. Янә сезне каберләрнең тигезлеге алдамасын, ни гаҗәп, ул кабердәге кешеләрнең бер-берсеннән аерылуы каты булды. Акыллы кешегә кабергә кергәнче үк, каберне күп итеп зикер кылу тиешледер», – диде».

(«Тәнбиһүл гафилин» китабыннан)

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА әзерләде

Мин = милләт

Асыл

Нигора Казанга 2018 елда килә. Нәҗип Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясен тәмамлаган. Мәктәптә балаларны скрипкада уйнарга өйрәтә. Җыр-моңга гашыйк кыз. Монысы – нәселдән, ди. Ул төрле конкурсларда катнашырга да өлгерә. Бию белән мавыга.

НИГОРА НУРУЛЛОЕВА, ТАҖИК, 25 ЯШЬ

Көндәлек тормышта милли кием киеп йөрим. Төрле зәркән эшләнмәләр тагарга яратам. **ТУГАН ҖИРДӘН ЕРАКТА БУЛГАНДА БУ АЕРУЧА КИРӘК. АЛАР ЯРДӘМЕНДӘ ҮЗЕҢНЕ ӨЙДӘГЕ КЕБЕК ХИС ИТӘСЕҢ**. Моннан тыш, үз милләтемне, үз халкымның мәдәниятен күрсәтергә мөмкинлек биргән чаралар булса, шуларда бик теләп катнашам. Фәнни эшләремне дә туган ягым Таҗикстанның мәдәниятен өйрәнүгә багышладым.

Дус-ишләргә Таҗикстан шәһәрләре турында, аның мәдәнияте турында сөйлим. Ихластан кызыксыналар! **АШ-СУЛАРЫБЫЗНЫ ЯРАТАЛАР. ӨЙГӘ ЧАКЫРЫП, КУНАК ИТӘРГӘ ЯРАТАМ.** Пылау, лагман, манты, ош пута кебек ризыкларны үз итәләр. **КУНАКЧЫЛЛЫК – КАНДА.**

КАЗАНДА, ГОМУМӘН, РЕСПУБЛИКАДА МИЛЛӘТАРА МӨНӘСӘБӘТЛӘРГӘ, ДУСТАНӘ МОХИТ ТУДЫРУГА АЕРУЧА ЗУР ИГЪТИБАР БИРЕЛӘ.

ХӘЗЕРГЕ МИН – ӘТИ-ӘНИЕМНЕҢ ТӘРБИЯ ҺӘМ ХЕЗМӘТ НӘТИҖӘСЕ. Аларның тырышуы, аларның үрнәге шәхес буларак формалашырга булышты. Минем әнием – татар, әтием – таҗик. Балачактан өч телне белдем, өч телдә сөйләштем.

Телне, традицияләрне саклауда буыннар арасындагы элемтә дә булыша. **ЯШЬЛӘР ӨЛКӘННӘРНЕ ТЫҢЛАРГА, ИШЕТЕРГӘ, АЛАР ӘЙТКӘНГӘ КОЛАК САЛЫРГА ТИЕШ, ДИП УЙЛЫЙМ.** Бу мөһим. Алар – тәҗрибә. Алар – нигез.

ТРАДИЦИЯЛӘРНЕ САКЛЫЙБЫЗ. Әйтик, рамазан аенда, Корбан бәйрәмендә, иртән торып, өйдә кызган таба, кызган май исе чыгару тиешле. Татарларда да бу традиция бар. Гомумән, бездә традицияләр шулкадәр күп! Туйларны гына алыйк. Авылы-авылы белән аерыла аңа бәйле гореф-гадәтләр!

ТЕЛ – ҮТКӘННӘРНЕ, БҮГЕНГЕНЕ ҺӘМ КИЛӘЧӘКНЕ ТОТАШТЫРУЧЫ КҮПЕР УЛ. Телне белү – ата-бабаларга, нәсел-ыруыңа, тамырларыңа хөрмәт билгесе. Тел аша мәдәният тә, тарих та, традицияләр дә күчә.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА әзерләде. Фото: Илдар МӨХӘММӘТҖАНОВ

6 сентябрь | Чәршәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 16+
07.00, 18.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 Утренняя программа «Здравствуйте!» 16+
09.00, 17.00 «ҖЫЛЫ ЭЗЛИ ҖАННАР». Телесериал 16+
10.00, 23.00 «ТАНКИ ГРЯЗИ НЕ БОЯТСЯ». Телесериал (субтитрлы) 12+
11.00 «Каравай» 6+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «АННА ГЕРМАН». Телесериал (татар телендә) 16+
13.00 «Җырлыйк әле!» 12+
14.00 «Туган авылым» 12+
14.15 «Если хочешь быть здоровым» 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Бергәләп әйрәник» 0+
16.00 «Переведи!» (учим татарский язык) 6+
18.00 «Таяну ноктасы» 16+
19.00 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Ак барс» – ХК «Сочи». Прямая трансляция 6+
22.00 «Вызов 112»16+
00.00 «Каравай». Восточные сказки в живописи 6+
00.25 «Соотечественники». Карл Фукс, которого любили все 16+
00.50 «Если хочешь быть здоровым» 16+
01.05 «Наша Республика – наше дело» 16+
02.00 «Манзара» 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлар белән) 16+
04.45 «Точка опоры» 16+
05.35 «Оныта алмыйм...» Ретро-концерт 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълумати- күңел ачу программасы 16+
08.00 «Утканнар сагындыра» 12+
08.40 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
09.40 «Йөрәктән – йөрәккә». Гөлзада Сафиуллина турында телеочерк (субтитрлы) 16+
10.40 «Туган авылым» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05 «Кунак БиТ шоу» 16+
15.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
16.30, 02.40 «Таяну ноктасы» 16+
17.00 «Музыкаль мәйдан» 16+
Дөрес, кайбер районнарда инде бәрәңгене үткән атнада ук ала башладылар. Социаль челтәрләрдә шундый видеолар, фотолар шактый күренде. «Шимбә-якшәмбегә дип ниятләп торган идек, ул көннәргә интернет яңгыр күрсәтә, корыда казуга җитми инде», – дип, дәррәү купктык. Бу атна ахырына бөтен кеше дә алып бетерәчәк, диләр. Анысы, берәү бакчага чыкса, бәрәңге ала башласа, ул элек-электән стартка бер сигнал кебек тоела иде. Әле кул белән казыган чорда ук, ялгыз әбиләр, кеше рәтенә җитешер өчен дип, алданрак кузгалсалар, алар артыннан ишле гаиләләр дә бакчага чыга иде. Хәзер дә шулай: авыл саен әллә ничә казыгычлы трактор булса да, аларга бу вакытта чират җыела, чөнки һәр кешегә бүген, нәкъ менә шушы сәгатьтә бәрәңге алдырырга кирәк булып чыга.

Гадәттә башка елны безнең яклар бәрәңгегә 30 август тирәсендә чыга һәм берничә көн эчендә алып та бетерә иде. Студентлар – шәһәргә, укучы балалар мәктәпкә киткәнче дип тә, ял көне булган өчен дә шул тирәдә бакчаларда чын өмә була иде. Быел бәрәңгеләр иртә утыртылды, көне тулды, артыгын торгызудан мәгънә юк дип, бер атна алдан кузгалдылар.

Бәрәңге вакытында, гәрчә бакчалар элеккедән бермә-бер кимесә дә, авыл кешесе йокы күрми. Казыгыч таккан трактор хуҗалары да (аларның әле шактые эш яшендә – хуҗалык эшенә барасылары бар, шуңа күрә иртән эшкә киткәнче, кайда төш вакытында эшлиләр) иртән дүртләрдә инде бакчада була. Килгән килеш бөтен бакчаны алдыртып бетерү өчен, хуҗалар агач тырмалар белән бәрәңгене бер буразнага җыя (икенче буразнаны алдырганда тапталмасын дип). Бу көннәрдә без дә шушы алым белән бәрәңге алдырдык. Иртәнге алтынчы яртыда инде тракторчы егет авылда өченче бакча булып, безнекен алырга керде. Башта күмәкләшеп бәрәңгене тарттык, инде җиде тулып үтешкә ун сутыйлы бакчаны чүпләп тә бетергән идек. Кыраү сукканны, чәчәк атмаганны, кирәк чагында яңгырга тилмереп утырганнарын исәпкә алсаң (әле азакка кадәр кортлар бимазалады үзләрен), уңыш сөенерлек.

– Ашыктыгыз бугай, күп өлештә бәрәңге сабагыгы ямь-яшел иде бит әле, – диючеләр дә булды. Әмма яшел сабакта да инде бәрәңге калмаган – барысы да купкан, тамырдан өзелгән. Утыртканга тиздән 120 көн була лабаса. Көне тулып үткән. Элек өлкәннәр, бәрәңге 90–100 көн үсә, диләр иде, галимнәр әле тагын унны өсти.

«Бакчадагы бәрәңгеләрне казып алгач, бөтен эш беткәндәй тоела», – ди авыл кешесе. Булганына шөкер итеп: «Черемәсен генә инде, үзебезгә насыйп булсын», – дип өстәп куя.

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

КЫР ШОНТАЛЫСЫ КЫРЫЛЫП ЭШЛИ

Безнең авылда 15 фермер хуҗалыгы бар, дигән сүзләрне ишеткәч, шикләнебрәк калган идем. Ни дисәң дә, 210 йортта 520 кеше яшәгән авыл турында сүз бара бит. Әмма дөрес хәбәр булып чыкты бу. Әле ул гына да түгел, тагын 10лап шәхси хуҗалыкта үзмәшгуль программасы буенча күп итеп мал-туар, кош-корт асрап, җирдә эшләп, үз көннәрен үзләре күреп яталар икән.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Остаз

Авыл халкы әйтмешли, кырылып эшли башлауларының сәбәпләре дә бар. Туксанынчы еллар Алексеевск районының Кыр Шонталысы авылына да үзгәреш җилләре алып килә: колхоз таралып, җирләрен «Кызыл Шәрык» компаниясе үзләштерә башлый. Шулвакыт, дәшми-тынмый калган кайберәүләрдән аермалы буларак, авылда каршы чыгучылар, җир дигән байлыкны үзләренә алып, маңгай тирен туган туфракка тамызуны дәвам итәргә теләүчеләр табыла. Тәҗрибә дә бар: колхозда төрле елларда механик, авыл советы рәисе, экономист, парторг, инженер булып эшләгән Шәүкәт Камаловның, пенсиягә чыгып, мәктәптә хезмәт укытучысы булып эшләгән чаклары. (Хәер, аның укучылардан аерылганы да булмый. 1960 елдан бирле өстәмә эш итеп, факультатив дәресләр укыта. Егетләрне механизатор итә, кызларны машина белән сыер саву һөнәренә өйрәтә.) Балалар эшкә өйрәнер, мәктәпкә матди ярдәм булыр дип, авыл хуҗалыгы кооперативы, ягъни фермер хуҗалыгы оештырып җибәрә ул. Шунда аңлый: азрак тырышып җибәрсәң, үҗәтрәк булсаң, җир хуҗасы булып эшләргә дә бик мөмкин икән бит. Шәүкәт абый соңрак, тәвәккәлләп, үзенә дә 160 гектар җир алып җибәрә. Эш башларга иске генә булса да чылбырлы ДТ, тәгәрмәчле «Беларусь» тракторлары бар. Үзенә исә бу вакытта, аз да түгел, күп тә түгел, 72 яшь тулган була инде.

Мәктәптәге фермер хуҗалыгының тагын бер файдасы тия: укучыларның күбесе, Шәүкәт абый әйткәнчә, чын җир кешесенә әйләнә. Аның үз улы Айрат та төп нигездә кала.

Шәкерт

Бүген туган җир туфрагына берегеп яшәүче Назыйф Кадыйров та – мәктәптә оешкан беренче фермер отрядыннан. Җир эшкәртеп йөрешләре. Бик кызыклы кына тәҗрибә ясаган алар. Каенеше Марат Сафиуллин, тагын бер туганы Хәннан Исмәгыйлов белән фермер хуҗалыгын бергәләп оештырганнар.

– 2018 елда өчәүләп шундый фикергә килдек. Ул вакытта хәтта бер тырмабыз да юк иде, – дип искә төшерә Назыйф. – Башта кредитка баттык инде. Грант отып, трактор алдык. Аннан акрынлап икенчесен, өченчесен булдырдык. Хәзер өчебез өч тракторда эшлибез. Өч ел элек комбайн алдык. Бөтен агрегатларыбыз бар. 300 гектарга якын җирне эшкәртәбез. Малларга печән, арпа, бодай үстерәбез. Өчебезгә 80 башка якын савым сыеры асрыйбыз. Хуҗалыкта үгезләр, таналар, кош-кортлар да үстерәбез. Җир үзебезнеке булгач, терлекләрне бушка ашатабыз дигән сүз бит инде. Бурычларыбыз бетеп килә инде, шуңа сөенәбез. Мал-туарны да ел саен арттыра барабыз. Тагын 150 гектар җир алырга да исәбебез бар. Тик менә бәяләр генә чабудан тарта. Арзан булса да, продукцияне сатарга туры килә. Башкача урнаштырып булмый бит, кредитларны түләргә акча кирәк.

Шундук күңелдә: «Барысын да ташлап, бу эшне туктатасы килмиме соң?» – дигән сорау туды. Бу сүзләрне ишеткәч, Назыйфның кояш астында йөреп каралган йөзенә елмаю менеп кунаклады:

> Безнең тамырларда крестьян каны ага бит. Бер тотынгач, бер дә ташлап китәсе килми шул. Авылда тор да җирдә эшләмә, имеш. Нәрсә була инде ул? Яшермим, арыган чаклар күп була. Әмма җирне ташлыйм дигән уй башка да кереп карамый. Ходай исәнлектән генә аермасын.

Татулык

– Шулай да куркып калучылар бик күп бит. Андыйларга нинди киңәш бирәсез? – дип сорыйм.

– Иң мөһиме, төшенкелеккә бирелмәскә дип уйлыйм. Тора-бара ярдәм итүчеләр дә табыла, җае да килеп чыга. Тагын бер киңәш бар: кеше сүзенә карамаска кирәк. Сөяксез тел ни сөйләмәс. Без дә ишеткәлибез. Бердәм булгач, арабыздан җил дә исми, – ди Назыйф егетләрчә. – Без хәзер дүртәү инде. Илнар Кыямов та кушылды. Бер-беребез белән киңәшләшмичә, берни дә эшләмибез. Иртә белән остаханәдә җыелабыз, сөйләшәбез. Уртак фикергә килеп таралышабыз.

Шундый ук татулык Назыйфның гаиләсендә дә хакимлек итә. Хәләл җефете Гөлия авыл кибетендә сату итә. Әмма ул аның берләнбер эше түгел. «Янында терәк булмаса, мондый зур эшкә тотынып булмый», – дип әйтеп тора Назыйф үзе дә. Иртә белән сәгать 4 нче 15 минутларда торалар да 15 сыерны саварга тотыналар икән. Кич белән тагын бер кат савасы. Терлекне карарга электр-көтүче ярдәмгә килә. Кич белән элеккеге гадәт буенча авыл кырыендагы чирәмгә чыгарабыз, ди.

«Син яшь әле...»

Без кырга, җир эшкәртүче Марат белән Хәннан янына юл тоттык. Шунда, сүздән сүз чыгып, Назыйф: «Сез яшь әле», – дигән сүз ычкындырды. Сорашып белдем: Назыйфка – 57, Маратка 48 яшь икән. «Назыйф абыйга рәхәт, шулай дип әйткән була. Ә мин менә бу сүзләрне беркемгә дә әйтә алмыйм, чөнки миннән дә яшьрәк кеше авылда механизатор булып эшләми дисәң дә була», – ди Марат, борчылып. Яшьрәкләр проблемаларны ачыктан-ачык әйтеп, ярып салалар кебек тоелды миңа.

– Эшләп торабыз әле. Ну, без эшләгәннең кадерен генә белмиләр. Бәяләрне генә карагыз инде. Сөтнеке 25 сумнан 18гә төште. Бөртеклеләрнең бәясе – 8 сум. Шул ук вакытта солярканың бәясе 51 сумга менде. Авыл кешесе түзә инде. Вакыт-вакыт миңа эшләп торган кешенең башына сугалар кебек тоела. Болай ярамый. Һәрнәрсәнең чиге булырга тиеш. Көн-төн эшләгәннең әҗере дә гадел булсын иде. Әмма зарланып та булмый. Эшли башлаганыбызга 5–6 ел гына булса да, шактый уңышларга ирештек. Бөтен әйберебез бар. Башкаларга ялынып йөрерлек түгел. Шул яшь дигәннән генә эчем пошып китте. Киләчәктә бу кырлар кем кулына калыр икән дип аптырыйм. Малай быел беренче сыйныфка керә. Минем эшләр белән кызыксынган була инде. Тракторга да, комбайнга да утыра. Ул үсеп җиткәнче, ниләр булып бетәсен кем белгән? – дип фәлсәфәгә бирелеп алды ул.

Ничек кенә булмасын, барысы да, дөньялар үзгәреп китсен дә авыл гына бетмәсен, дигән теләктә яши. Без дә, мондый кулыннан алтын тамган кешеләр дилбегәне тиз генә кулларыннан ычкындырмаслар, дигән уй белән киттек Кыр Шонталысыннан.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

РОССИЯ ГЕРОЕ РӘСИМ БАКСИКОВНЫҢ ӘНИСЕ:

«УЛЫМ ЧЫН ИР ИКӘН, ДИДЕМ»

«Әтисез үсте. Кыек юлдан китмәсен, тормышта үз урынын тапсын өчен мин көчемне кызганмадым. Балам белән бик горурланам». Күптән түгел Россия Герое исеменә лаек булган Татарстан егете 34 яшьлек Рәсим Баксиковның әнисенең сүзләре бу.

Милләте буенча чуаш булган Розия ханым теттереп татарча сөйләшә. Рәсим катнаш гаиләдә туа. Әмма гаилә малайга өч яшь вакытта таркала. Шул көннән башлап, тормышның бар авырлыгы кечкенә генә гәүдәле ханым җилкәсенә өелә.

– Иремнән киткәндә, олы кызыма 11 яшь иде. Әни безне үз янына чакырды. Алексеевск районының Биләр бистәсендә иске генә йорт алып бирде. Мин ике балам белән шунда күченеп кайттым. Ул чакта тормыш җиңелләрдән түгел иде. Ничек тә аякка басарга, балаларны кеше итәргә кирәк. Җитмәсә, ир балага ата тәрбиясе дә юк. Улым бик шук иде. Тик тормады. Дуслары белән әллә кайларда йөрер иде. Бездә бит «Изге чишмә» бар. Әнә шундагы агач башларына да менеп китәрләр иде. Рәсим кечкенә вакытта усал да булырга туры килде, яратып сыйпап кына тормадым. Мин әни дә, әти дә идем, – дип искә ала Розия ханым.

Розия ханым көне-төне эштә була. Балаларына бер генә әйтә ул. Алар әниләрен аңлый, тыңлый. Рәсим исә 12 яшендә, үскәч хәрби булам, ди.

– Биләр мәктәбендә Андрей Чугуров дигән укытучы укыта. Ул заманында директор да булып торды. Малайларга хәрби патриотик дәресләр бирә. Аның янында тәрбиягә авыр бирелүче, тәртипсезрәк малайлар да булыр иде. Әтисезләргә әти булды, балаларны туры юлдан алып китә алды. Чын ир-ат итеп үстерергә булышты. Рәсимнең һәр уңышында аның да өлеше бар дип саныйм, – ди Розия ханым.

Мәктәп елларында Рәсимнең үзенә дә Андрей Чугуров янында йөрү ошый. Ул аңа ияреп эзләнүләргә дә чыгып китә башлый. Укуны тәмамлаганда, бер теләге була – Казан танк училищесына укырга керергә! Тик язмыш син әйткәнчә генә булса иде дә бит. Рәсим бер имтиханына бармый. Әллә оныта, әллә килеп җитә алмый. Анысын инде Розия ханым хәзер хәтерләми дә. Шулай итеп, егеткә хәрби булу турындагы хыялын бер елга кичектереп торырга туры килә. Токарьлыкка укырга керә ул.

– Анда укуы уку булмады инде. Тәмамламады да ул аны. Аның бит бар теләге хәрби булу иде. Шул хыял белән яшәде. Ятса да, торса да, уенда танк училищесы иде. Иленә елга барыбер шунда укырга керде. 3 курста укыганда өйләнде. Укып бетергәндә улы Данил туган иде инде, – ди әнисе.

Владимир Путин батыр якташыбыз һәм аның иптәшләренә Алтын Йолдыз орденын 24 августта Курск өлкәсендә тапшырды. Икенче көнне Россия Президенты Кремльдә алар белән кабат очрашты.

Өйне сатып, балалар янына

2010 елда Рәсимне Читага җибәрәләр. Аннары Хабаровскида хезмәт итә, соңрак Владикавказга барып урнаша. Рәсим кайда – гаиләсе шунда. Хатыны Анастасия улы белән ире артыннан калмый.

– Улымның малае авыру туды. Шуңа да киленем гомерен шул бала белән уздыра. Аны тәрбияли. Бервакыт Данил авырып китте. Ул чакта Анастасия икенче сабыена авырлы иде. Хабаровскида яшәгән балаларыма минем ярдәмем кирәк булды. Инде нишләргә? Кулымда акчам да юк бит. Озак уйламадым, Биләрдәге йортымны саттым. Йортны саткан акчага улым гаиләсе янына бардым. Онытым белән хастаханәдә яттым. Хабаровскида 2 ай торып кайттым. Ул вакытта мин инде Биләрдән Казанга күченгән идем, – дип сөйли Розия апа. – Рәсимнең хәрби тормышы 3 еллап туктап торды. Ул эштән киткән иде. Балачактагы хыялы әнә шулай тиз сүрелде дип тә борчылдым. Күңелдә авырлык бар иде. Гомерем буе улымны батыр итеп күрәсем килде.

Розия ханымнан Рәсимнең кечкенә вакытларын сорашам. Әйткән сүзен үтәү, үҗәтлек кебек сыйфатлары элек тә булганмы?

– Улым кечкенәдән курку белмәде. Дусларын да яклар иде. Кулына тотып, кәлтә, бакалар алып кайтыр иде. Әбервакыт ул урам буйлап дуңгызларыбызны куып йөргән. Хәзер шул чаклар искә төшә дә күңел тула. «И сабыем!» – дим! Барысы да шул акча юклыктан килеп чыккан хәлләр бит инде. Гаиләне яшәтер өчен дуңгыз асрый идек. Мин өйдә юк. Дуңгызлар лапастан чыгып кача башлаган. Рәсим югалырлар дип курыккан. «Булышыгыз, зинһар», – дип, кешеләрдән ярдәм дә сораган. Үзе дә кайберләрен тотып, кире алып кергән. Хәлдән тайган иде. Кечкенәдән җаваплылык хисе дә зур анда.

Махсус хәрби операция башланугa Рәсим яңадан эшкә урнаша. Әнисе улының бу адымын күреп соклана, горурлана.

– Улым чын ир икән, дидем. Илдә шундый хәл булсын да, хәрби була торып, качып ята алмый бит инде. Мин аның бу адымын ук батырлыкка тиңләдем. Әлбәттә, югалтырмын, ни булмас, дип тә уйладым. Елаган чаклар да булды. Әмма бар күз яшен елмаю, шатлану җиңде. Күз карасы кебек саклап, кадерләп үстергән улым иле өчен утка керә, дидем. Күңелдәге хисләрем ташый иде, – ди ул. – Улларын көтүче әниләргә сабырлык телим. Ничә яшьтә булсалар да, алар безнең өчен һаман сабый әле. Җиңеп кайтасыларына ышанырга кирәк.

Рәсим махсус хәрби операциягә киткәч, аның гаиләсе дә Казанга күченә. Монда фатир алалар. Анастасияне каенанасы мактап кына тора. Бөтен тормыш бер үзендә, ди.

– Улым акчалата булыша, киленем бар җирне тәртиптә тота. Әле менә бу көннәрдә кайгылы чагы. Кодабызны җирләдек. Яман чирдән китеп барды. Аны озатырга Рәсим дә кайтты. Ялда булам, ди. Бер генә күрештек. Әле рәхәтләнеп, табын янына җыелып сөйләшеп утырганыбыз юк, – ди Розия ханым. – Телевизордан Россия Президенты Владимир Путин улыма Россия Герое исеме биргәнне карадым. Рәсим алданрак, әни, мине бүләклиләр, ахрысы, дип сиздергән иде. Ул чакта ышанмадым. Инде ничә еллар өлкән лейтенант бит ул. Мин аңа берәр хәрби исем бирәләр дип торам. Үз күзләремә ышанмадым. Улымны экранда күрүгә, елый башладым. Ул безне бөтен илгә танытты. Миңа журналистлар белән сөйләшергә дә кыен. Моңа кадәр кешегә күренеп йөргәнем юк иде. Гап-гади штукатур-маляр бит мин.

Рәсим Путинны бик ошатып кайткан. «Бигрәк гади кеше икән. Тыныч, акыллы», – дигән.

– Аңа бит Президент сәгать тә бүләк иткән. Шуңа карап кына тора инде. Улымның бу мактаулы исемендә Андрей Чугуров өлеше дә, танк училищесы укытучылары өлеше дә бар. Әлегә мин улымның ни өчен Герой булганын белмим. Үзе күп сөйләшми. «Бу – безнең егетләр белән уртак эш», – дигән була. Тиздән күрешәбез. Улымның нинди батырлык кылуы турында шунда сорармын инде, – ди әнисе.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Рәсим Баксиков нинди батырлык эшләгән соң? Җәй уртасында интернетта пилотсыз очкычтан төшерелгән видеоязма пәйда булды. Анда Т-80 танкының дошманның берьюлы 8 бронемашинасына каршы чыгуы сурәтләнә. Якташыбыз «Алеша» исеме бирелгән әнә шул танк белән идарә итә дә инде.
Россия Оборона министрлыгы хәбәренә караганда, әлеге вакыйгага кадәр безнең танк дошманның артиллерия уты астында кала. Яраланган танк йөртүче-механикны табиблар кулына тапшырып, егетләр мотоукчыларга ярдәмгә ашыга. Экипаж командиры Рәсим Баксиков вазыйфасын лейтенант Александр Леваковка йөкләп, йөртүче-механик урынына үзе утыра. Танк орудиесе белән наводчик Алексей Неустроев идарә итә. Менә шунда алар каршысына дошман техникасы килеп чыга. Артка чигенеп булмый, егетләр дә куркып калмый. Безнекеләр санаулы минутлар эчендә каршы якның 2 танкын һәм 6 бронетранспортерын, күп санда сугышчысын юкка чыгара. Соңрак аларны башка танк алыштыра. Әмма ул каршы як һөҗүменә дучар булып, сафтан чыга. Рәсим Баксиков экипажы кабат ут астына кереп, икенче танкны тарттырып тыныч урынга алып чыга.
Оборона министры карары белән батыр егетләр Россия Герое исеменә тәкъдим ителгән, Рәсим һәм аның иптәшләре турында бөтен ил белде. «Үземне герой дип санамыйм. Без бит эшләдек. Эшебез шундый», – диде сөйләде якташыбыз журналистларга. Аннары: «Бәрелеш вакытында ниләр кичердегез?» – дигәнгә, шаяртып: «Бик кызу булды. Танк эчендәге кебек», – дип җавап бирә.

Сан

Казан танк училищесын тәмамлаучыларның 39ы Советлар Союзы Герое исемен йөртә. Махсус хәрби операция башлангач, биредә укыган 11 егет Россия Герое исеменә лаек булды.

ЛИЛИЯ ФӘТТАХОВА:
«МИНЕ, ӘЙЕ, ИРЕКЛЕ, ДИП ӘЙТЕРГӘ БУЛА»

Язасым килә икән – язачакмын! Язучы Лилия ФӘТТАХОВА-ның сүз уңаеннан гына әйткән бу сүзләре аның бөтен асылын ача да сала. Усал шигырьләре, тирән мәсәлләре (сүз уңаеннан, татар әдәбиятында бу жанрга бүтән алынучы да юк бугай инде), тормышчан хикәяләре белән дә, балалар өчен язылган әсәрләре белән дә күптән телгә керде инде ул. Ә бу әңгәмә – ирек һәм хөрлек турында.

:: «Мәгърур басып кына исем килә, җисеме әле килеп җитмәгән...» дигән юлларның авторы усалдыр. Һәрхәлдә, шулай тоела. Дөресе шулмы?

– Усал түгел. Җәмгыятьтәге җитешсезлекләрне кайвакыт көлемсерәп, кайвакыт әрнеп, ачынып күзәтүче тәнкыйтьче утыра минем күңелдә. Бик нечкә, йомшак күңелле ул үзе. Менә бу шигырь мин Яңа Чишмәдә мәктәптә эшләгән чакта язылган иде. Кайдандыр, Казаннан булса кирәк, бер «ревизор»ны көтәләр: баганалар агартыла, юл кырыйлары чабыла, ауганы торгызыла... Ә нишләп шул бер кеше өчен эшләнергә тиеш соң бу эшләр? Ә нигә шул җирдәге йөзләгән кешене шундый матурлык, төзеклектә яшәтмәскә?

Мәктәптә эшләгәндә, Укытучылар көненә балалар газета чыгарган иде. Шунда һәрбер укытучының фотографиясе, исем-фамилиясе язылган да аста буш урын калдырылган: теләгән укучы үзенең бәясен бирә ала. Минем өчен «кырыс, ләкин иң гадел укытучы» дигән бәя бик кадерле булды. Хәзер уйлыйм: минем ул кырыслык та битлек кенә иде бит. Йомшак булып кара мәктәптә, шунда ук җилкәңә менеп утыралар. Ә мин бит әле – бик җаваплы, таләпчән укытучы кызы да: минем дәрестән бала нинди дә булса белем алып китәргә тиеш, дип саныйм. Балаларның тормышка карашларын билгели торган тарих белән җәмгыять белеме фәннәре бит!

:: Шулай да Чаллы язучылары усалрак, кыюрак, ирекләрәк, дигән фикер дә бар бит әле.

– Әйбәт фикер бу! Язучы шулай усал, кыю, ирекле булырга тиеш инде ул. Иң беренче чиратта – ирекле. Ләкин мин, зурдан кубып, алай чагыштыра алмам. Чагыштырыр өчен Казан язучыларын, төрле төбәк язучыларын әйбәт белү кирәк. Әйе, бездә легендар Айдар абый Хәлим бар! Әйе, бездә теләсә нинди милли мәсьәләдә үзенең кыю, анык фикере булган Лилия Гыйбадуллина бар. Әйе, бездә ир-ат язучыларның күбесеннән кыюрак, көчлерәк рухлы Фәүзия апа Бәйрәмова бар. Иң ирекле язучы – улдыр, мөгаен. Ләкин... Тукай премиясен бирделәрме? Китаплары дәүләт нәшриятларында басыламы? Мәктәпләргә очрашуларга йөри аламы? Нәтиҗәне үзегез ясыйсыз инде. Безнең ирек хакимият ясаган калыпка кертеп утыртылган күләмдә генә ул: гомуми кабул ителгән фикердән үзгәрәк фикерләрең белән газета-журнал битләренә чыгу, радио-телевидениегә, ягъни халык белән аралашуга чыгу мөмкинлегең юк диярлек.

Мин якташым, детективлар язучы Шамил Шәйдуллинның хатыны Фиалка ханым белән аралашам. Ул еш кына: «О, Шамилләр вакыты! Фаяз Дунайлар, Игәнәйләр вакыты! Чаллы гөрләп торды! Бөтенләй башка рух иде ул вакытта. Хәзер алай түгел», – ди. Мин ул еллардагы Чаллыны белмим. Ләкин безне, беренче курс студентларын, Ирек мәйданына алып баралар иде. Ә анда безнең яңа тарих язылып ята. Дистәләгән автобус белән чаллылылар килә: алар шундый гаярьләр, кыюлар кебек тоела иде. Туксанынчы елларга яраган хәзер ярамый инде ул. Хәзер каш ясыйм дип күз чыгарырга мөмкинсең ул кыюлык белән.

Мин белгән Чаллы язучылары тату, бердәм, ярдәмчел. Бүгенге вазгыятьне аңлаган хәлдә телне саклау өчен тырышалар: очрашуларга йөриләр, кичәләр үткәрәләр, яңа проектлар белән яшьләрне җәлеп итәргә омтылалар. Бирелдә әле «Көмеш кыңгырау» республика балалар һәм яшүсмерләр газетасы да бар. Татарча язган һәр баланың кечкенә генә уңышына да бергә куанабыз, аларны сакларга, үстерергә тырышабыз.

> Ирек ул – үзеңнең вөҗданың кушмаганны эшләмәү мөмкинлеге. Кешеләр бит бик төрле: яшәү рәвешләре, уйлау рәвешләре, дөньяны кабул итү рәвешләре белән төрле. Яралтучы шулай төрле итеп яралткан безне. Минем өчен менә шул төрлелекне саклау мөмкинлеге ул ирек.

:: Лилия Фәттахова дигән язучы бүген үзен ирекле дип саныймы? Юк икән, ирекле булыр өчен ни кирәк?

– «Юк, әлбәттә!», – димәкче идем дә, «Әйе, ирекле», – диеп тә була икән. Киң төшенчә бит ул. Бүгенге вазгыятьтән бәйсез түгел мин. Үз уемны Эзоп теле аша җиткерсәм генә. Үзеңне ирекле сизәр өчен, финанс ягыннан да шактый бәйсез булуың кирәк. Ул яктан Телләр комиссиясе үткәргән бәйгедә җиңүем миңа кечкенә булса да финанс мендәре булдырырга ярдәм итте. Бүген үземнең туган ягымда яшим. «Үземә җәй булак иттем». Кызыксынучыларга шулай җавап бирәм. «Мәйдан» журналының баш мөхәррире вазыйфасыннан киттем. Ул да минем үзем ирекле рәвештә кабул иткән җитди карарым иде. Хәзер менә татар язучысы профессиональ язучы буларак кына, беркайда да рәсми эшләмичә, үзен тәэмин итә аламы икән – шуны ачыклап карарга исәп. Әдәби-иҗади отпускыны бер елга озайтырга булдым әле, җәйге ирегем ошап китте. Әгәр карарларны үзем тиеш санаганча кабул итә алам икән, димәк, мин чагыштырмача ирекле. Әгәр газета-журналларга язып, конкурсларда катнашып кына яшәү мөмкин икән, димәк, бу минем ирегемне арттыра дигән сүз.

Әле бу җәйдә иҗатның «тәрҗемә» дигән тармагы белән дә танышырга туры килде. Ркаил абый Зәйдулла узып барышлый гына күреп алды да: «Син бит – профессиональ язучы хәзер, вакытың күп, әйдә, Рәсүл Гамзатовның «Мой Дагестан»ын тәрҗемә ит әле», – ди. «Укыганың бармы бу әсәрне?» – ди. «Юк», – мин әйтәм. «Ничек инде язучы башың белән «Мой Дагестан»ны да укыганың юк?» – ди. «Менә шулай инде», – дим. Ә ул: «Ярар, тәрҗемә итә-итә укырсың», – ди. Бер көн уйладым да алындым бу эшкә. Миндә шундыйрак сыйфат бар: ниндидер яңалык белергә, өйрәнергә мөмкинлек туган икән, димәк, аны сиңа Аллаһ алга таба үсеш өчен биргән, дим дә тәвәккәллим. Җәемнең тулы бер ае шуңа багышланса да, үкенмим: мин ул әсәрне, ул әсәрне язучыны, шундый милли рухы булган халыкны нык яраттым. Бездә ул рух – куян шулпасының шулпасы гына. Бер генә мисал китерәм. Атаклы Шамилнең улы Җәләлетдинне сигез яшеннән тотык итеп алып китәләр. Ул егерме дүрт яшендә, рус офицеры булып, «Патша бөек, бай һәм көчле; ни өчен без бу тауларның фәкыйрьлеген, караңгылыкны якларга тиеш? Россиядә бөек әдәбият, бөек музыка, бөек тел бар. Дагыстан Россиягә кушылса, отачак кына» дигән уйлар белән кайта. Офицер киемнәрен суга ташлатып, үз халкының киемнәрен кидертсә дә, башына кереп утырган ул уйларны куып чыгара алмый инде атасы... Менә шундый фаҗига. Бу – уналты ел чит тәрбия алу нәтиҗәсе. Ә безнең фаҗигаңең уналтынчы гасырдан башланып йөз елларга сузылуын исәпкә алсак, әле дә исән әле без! Безнең «Җәләлетдин»нәребез дә меңләгән бит инде хәзер. Һәм бу табигый да.

:: Тапталган сорау инде: китап чыгару язучыны бәхетле итәдер, әмма китап укучы бармы бүген?

– Кешелекнең аңлы чоры Сүздән киткән һәм Сүз белән төгәлләнер дә инде ул, димәк, бөтенләй китап укымауга барып җитә икән, юкка чыгуга да ерак калмаган дигән сүз. Китап укучы даирәсе бүген кечерәя бара, ләкин ул татарның азаюына пропорциональ дип уйлыйм.

:: Тагын биш елдан китап укучы булырмы?

– Биш елдан әле хәлләр танымаслык дәрәҗәдә үзгәрмәс кебек. Укый торган урта һәм өлкән буын бар бит. Егерме-утыз елдан соң, аларның күбесе бакыйлыкка күчкәч, бушлык ачыграк күренер дип уйлыйм. 2017 елгы мәктәпләрдәге «тел белән эксперимент»ның аяныч нәтиҗәсе – әдәби әсәрләр укып ләззәт алырлык, тәэсирләнерлек яшьләрнең коточкыч дәрәҗәдә азлыгы күренәчәк. Караңгырак минем фараз. Татар тарихы укытылмавы да оптимизм өстәми. Балаларга төп фәннәр, шул исәптән тарих, җәмгыять белеме туган телләрендә укытылмый икән, аларның үз телләрендә мантыйкый фикерләве мөмкин түгел. Мин инде милли үзаң үстерү турында әйтмим дә. Нәрсәгә нигезләнеп, үз-үзләрен хөрмәт итәрлек дәрәҗәдә яратсыннар соң әле алар ата-баба тарихын, аның кыйммәтләрен?! Беренчедән, алар аны өйрәнмиләр, икенчедән, алар бар да – бүгенге көн «Җәләлетдин»нәре бит. Кем арбасына утырсаң, шуның җырын җырлыйсың. Ә әлегә безнең балаларның безнеке булуы өчен мәгариф системасында милли җанлы ата-аналар да, шундый ук фидакарь укытучылар гына тырыша. Соңгы елларда радио-телевидение, газета-журналларда милли проектлар артты, бик хуп. Ләкин алар гаилә белән мәктәпкә өстәмә ярдәмче генә була ала.

Туксанынчы елларда үзем эшләгән мәктәптә булган бер хәл искә төште. Бер укытучы, татарларга карата тискәре мөнәсәбәтен күрсәтеп, нинди-дер ямьсез сүз әйткәч, Илназ исемле малай, төркемдәге бөтен татарларны җыеп, дәрестән алып чыгып киткән иде. Укытучы, хатасын таныпт, гафу үтенгән иде. Менә шундый рухлы ба-

лалар елдан-ел азая бара. Вазгыять кискен үзгәреп, яңа шартлар туса гына, хәлләр уңайга үзгәрер кебек. Ул вакытта инде «Татар әдәбиятының укучысы булырмы?» – дип борчыласы калмас. Татар – мәгърифәтле халык ул, үз-үзенә реанимацияне тиз ясар.

:: Сезнең иҗатта кулланыштан төшеп баручы «мәсәл» дигән жанр да бар. Бу да бит хәзерге заманга бик килешеп бетмәгән туры сүзлелекне, кыюлык һәм усаллык таләп итә...

– Алдарак әйткәнемчә, бу – ваемсыз, гамьсез булмыйча, җәмгыятьтәге гаделсезлекләрне күрү һәм башкаларга да күрсәтергә тырышу. Мин үземне кыю дип санамыйм. Бөтенләй юаш, куркак булмасам да, көчле көрәшче дә түгелмен. Минем мәсәл язуым яки башкаларның шундый тәнкыйдирәк әсәрләр язуы ул – пар чыгарып алу гына. Шуның белән шул.

Аларның тәэсир көче бүген юк дәрәҗәсендә тоела миңа. Ак белән кара буталып беткән заман. Кеше үзенә Аллаһтан бирелгән иң зур бүләкне – уйлау сәләтен кулланса гына, үзе һәм иле өчен җаваплылыкны үз өстенә алса гына, мондый мәсәлләрнең дә җәмгыятьне яхшыртуда өлеше булыр, дип өметләнәм. Ләкин яхшы заманнарны көтеп кенә яхшы заманнар килми инде ул, моның өчен барыбер кулдан килгәнчә тырышырга кирәк. Сүз беләнме, гамәл беләнме Җирдә яхшылыкны арттырасы бар. Мин хәзер «коллектив аң, уңай корылышлы энергия» дип әллә нинди темаларга кереп китмәм инде, шуңа гына инанам бүген: сүгеп кенә җәмгыятьне үзгәртеп булмый (шулай ук кешене дә), булдыра алган кадәренчә игелекле гамәлләр кылырга кирәк.

:: Язучыны түрә итсәләр (мәсәлән, сезне), тормышта нәрсәне үзгәртер иде?

– Һәркем үз эшен эшләсен инде ул, үзенең кулыннан килгәнне. Системада бер шөреп кенә бит ул түрә, язучымы-түгелме – барыбер. Язучы, әлбәттә, ул системага барып эләгә икән, тел-әдәбиятка бәйле проектларга керешер иде. Керешеп карар иде.

:: Әле кичә генә Республика көне иде. Нинди хисләр калдырды быелгы бәйрәм?

– Минем өчен абсурд бәйрәм ул. Нәрсәне бәйрәм итәбез соң без, кайсы уңышыбызны? Балаларга бер риваять сөйли идем. Сталин үзенең ярдәмчеләренә ничек идарә итәргә кирәклеген өйрәтмәкче була. Бер тавык тотып китерергә куша. Аннары аның йонын йолкырга куша. «Карагыз хәзер!» – ди. Мескен тавык, кая барырга белмичә, салкыннан дердер калтырап басып тора да тиранның күн итегенә килеп елыша. Сталин аны этеп җибәрә, тавык һаман саен аның аягына килеп чүмәшә. Аяк тирәсендә аз булса да ышыграк, җылырак бит.

Кыскасы, минем өчен бәйрәм түгел бу. Урам тутырып, татар балалары татарча сөйләшеп йөрсә, татарча җырлар яңгырап торса, татар кинофильмнары аншлаг белән барса, авылларда эш урыннары булдырылып, мәктәпләр сакланып калса һ.б. – бәйрәм көн шуннан соң башланыр иде.

:: Иң зур теләгегез нинди?

– Менә алда әйткән бәйрәм көнен күрү. Дөньяның акылына килеп, дошманнар түгел, дуслар эзләгән көнен күрү.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

ЛИЛИЯ ФӘТТАХОВА

«СЕЗДӘ НИНДИ ХӘЛЛӘР БАР?..»

< Ахыры. Башы 25 август санында

Күзгә эңгер-меңгердә юл тирәли үсеп утырган агачлары да шомландыра, тоташтан каралып утырган тәбәнәк кенә өйләрдә инде утлар алына башласа да, алар зират өстендә ялтыраган утлар кебек, куркудан кала берни дә бирми күңелгә. Мин үземне болай ук куркакмындыр дип уйламаган идем. Нидән куркам, үзем дә белмим. Бу төрмә түгел, монда бары шул төрмә-лагерьлардан азат ителгәннән соң яшәп калган кешеләр генә инде хәзер. Фирая шулай дигән иде. Шүрләтә и все тут!

Юлда очраган ике карчыктан үземә кирәкле кешенең кайда торганлыгын сорыйм. Ярым җимерек каралты-куралы бер йорт икән. Монда андыйлар күп күренә. Тәрәзәсендә ут бар, димәк, өйдәләр. Башта шалтыратырга кирәклеген хәзер генә абайлап алам. Ярый ла беркая да китмәгәннәр.

Эчтән бикле ишек аша гына кемлегемне, нишләп йөргәнлегемне аңлатам. Ишек ачыла. Каршымда – миңа кирәкле Алексей дигән карт. Кыяфәтенә караганда, җитмешләрнең өстедер: бөкрәебрәк атлый, йөзен тирән-тирән буразналар сызгалап бетергән. Бөтен киеменнән арзанлы тәмәке исе аңкый. Ул ис безгә ияреп кердеме, киемгә ияреп чыккан идеме – бөтен тирәдә икән. Әлеге тәмәке исенә килеп кушылган әчкелтем-төчкелтем кәбестә, суган, кайдадыр быгыр-быгыр кайнап утырган нәрсә (әллә самогон инде?!) исләрен сизеп, укшыр дәрәҗәгә җитсәм дә, чыгып китә алмый идем инде.

Без өйдә икәү генә икәнбез. Карчыгы күршегә кереп киткән, ди.

– Я знал, что кто-нибудь приедет и заберет его вещи. Рука как-то не поднималась выкинуть... Әбиләрнеке же все таки...

Мин, аптырап, Алексей картка карыйм. Аның авызыннан чыккан татар сүзе бу мохиткә, бу йортка һич кенә дә туры килми, ят, чит булып яңгырый.

– Аухади мин. Тоже татар. Но теперь уже – ... ул туктап калды. – Синен атиен белян сидели. Монда бергя эшлядек.

Карт, миңа көтеп торырга кушып, каядыр чыгып керде. Кергәндә, ян-яклары кыршылып беткән чемодан иде кулында. Ул аны урындык өстенә куеп, сакланып кына ачты да шуннан бер кечкенә генә төргәк алып, миңа сузды. Берничә кат полиэтилен пакет эчендә... мин эзләп килгән хәтер иде. Фотосурәттә – без, беренче тапкыр дүртәү төшкән кәртечкә иде бу. Әнкәйне утырта алмаган иделәр янныбызга, сурәткә төшәргә гомер-гомергә яратмады. Ә безнең барыбызның да авыз ерык, өстебездә – Сабантуйга дип алынган киемнәр. Кечкенәбез Нил генә астан карый, утыруы да бераз җайсызрак, минем итәктән яртылаш шуып төшкән.

Күзләремә яшьләр тыгыла. Алексей-Әухәди миңа чәй кабының ялтыравык кәгазе белән тышланган бер китап суза. Кулыма алганчы ук мин инде аның әбекәем кулыннан да төшермәгән догалар китабы икәнлеген аңлыйм. «Бисмиллә...» Күзләремә бөялгән яшьләр тамак төбемә килеп утыра, чит-ят кеше алдында йомшаклыгымны күрсәтәсем килмәгәнгә, китапны алып, читкәрәк китеп утырган булам. Күз алдымда гарәп хәрефләре биешә. Ии әбекәем, йомшак күңелле, ышанучан әбекәем. Яман кешеләрдән, яман уйлардан саклап йөртсен, дигәнсеңдер инде. Нинди генә булса да, кайда гына булса да, газиз балаң ич ул синең. Озаклармый үләсеңне сиздең микән әллә?..

– Ты не обижайся на отца. Хороший он был человек.

Минем ачы итеп көлемсерәгәнне күреп алдымы, карт телен вата-җимерә биредәге хәл-әхвәлләрне сөйләргә ашыкты:

– Кулы алтын иде атаннын. Беля иден, что ул слесарь, токарь эйбят? Мичтә чыгара, и кузнец отменный. Кулы эш белгән кешене лагерьда да күреп алалар ул. Атаңа өч кешелек бригада атьканнар создавать. Ул мине и тагын бер землякны сайлап алды. Биредәге бөтен строительный-ремонтный эшләрне башкардык без. Бу якларда ведь эш осталары яшәми, андыйлар сирәк. Язмыш корбаннары яши монда. Судьбинушка закинула всех сюда.

Каты бәреләсем килмәсә дә, йөземә чыккан көлемсерәүне яшереп кала алмадым кебек тагын.

– Гаепсез кешене хөкем итмиләр ул, диясеңдер инде. Утыра шул, братишка! Утыра... Менә атаңны кара. Лесничийдан язу алдык дип алдап, танышлары урман кистерә аңардан. Подмога, имеш. Ә аннары, тотылгач, бөтен гаепне аңа аударып калдыралар. Кызурак канлы иде атаң, ул аты-юлы белән сүгенеп, тикшерергә килүче милиционерларның ачуын чыгармаса, бәлки, эзенә төшәрләр дә иде, кем белә.

Мин бу кадәресен белмәгән идем.

Пакет төбендә ике хат ята икән. Таныш кул! Әнием хаты.

Әти турында сөйләгәннәрен дә яратмаган әни аңа лагерьга хат язганмы? Кабалана-кабалана хатны укырга керешәм. Әни гадәттәнчә коры гына безнең хәл-әхвәлләрне тезгән. Минем ялга кайтып китүемне дә әйтеп үткән. Берничә күрше турында язган. Соравыма җавап хатның соңгы юлларында икән: авылдагы йортны сатарга исәпләгәннәр дә, әтинең ризалыгы кирәк булган. Имәндә икән чикләвек!

Икенче хат безнең элек яшәгән адреска язылган. Мондый язуны күрсәләр, укытучылар балаларны: «Аякларың белән яздыңмы әллә?» – дип тиргәрләр иде. Хәрефләр тигезле-тигезсез, төрле рәвешләргә кереп әле уңга, әле сулга авышып киткән. Кызыксынып, ачып укый башлыйм. Әти мәрхүмнән икән. Кулы эш белсә дә, кәгазь-каләм белән бик дус түгел икәнлеге күренеп тора. Ярты бит булып тезелгән сәламнәрдән соң минем йөрәгемне кысылып куярга мәҗбүр иткән сүзләр тәгәрәп ята:

«Сагынам мин, Оркыя. Балаларны сагынам. Авылны төштә күрәм. Сабантуйга чыгып, туганнар белән гөрләшеп, җырлап-биеп кайтасым килә.

Бездә биек таулар бар ла,
Тау астында таллар бар.
Талда яфрак, миндә сагыну,
Сездә нинди хәлләр бар?

Шулай җырлый иде зимагур Хәсән, син аны хәтерләмисеңдер инде. Аның хәленә калырмын дип кем уйлаган.

Нишлим соң? Сихерләгән кебек бит бу Нюра. Көндез күземә гап-гади ямьсез марҗа кебек күренә, төнлә тагын шуның белән ятып йоклыйм».

И әти, әти! Сине гомер буе кичерә алмаган әнигә шундый сүзләр язалармыни? Әле ярый җибәрмәгәнсең.

– Ә кем иде ул Нюра? – дип сорыйм Әухәди карттан. Аңлыйм инде юкса, биредә шул хатынга йортка кергән булган.

– Бик әйбәт хатын иде ул Нюра. Ничек килеп эләккән булгандыр монда, анысын хәтерләмим дә инде. Бик йомшак телле иде. Атаң да «голубчик мой», «золотой мой» дип кенә торды ул. Кечкенә генә эшен дә күп итеп күреп мактый белә иде. Без бит хөкүмәт эшен дә эшләдек, ялгыз хатыннарга, карчыкларга да кулдан килгәнчә булыштык. Кайсының миче тартмый, кайсының үтүге ватылган, кайсына чиләк төбен ямап бирергә кирәк... Шулай танышып киттеләр инде Нюра белән дә. Ялгыз иргә тәмле телле хатыннан да якынрак кеше була аламы чит-ят җирдә? Ашарына пешерде, керен юды. Тагын ни кирәк?

Мин кайтырга кузгалам. Алексей-Әухәди, куна кал, дип кыстаса да, хатирәләр биштәре белән бу укшыткыч исле йортта кала алмасымны аңлыйм. Миңа кайтырга кирәк.

Ишегалдына чыгып, күкрәк тутырып кичке һаваны суларга да өлгермим, капкадан лаштыр-лоштыр итекләрен сөйрәп, Алексейның карчыгы кайтып керә.

– Ты что ж, Лексей, гостя на ночь глядя отпускаешь? Нет-нет... Пойдем-пойдем, посидим-поговорим, сын нашего Толи – нам не чужой человек.

Йөз дә бер сәбәп уйлап чыгарып, марҗа карчыгы белән дә саубуллашам. Аның аркамнан сөяргә дип күтәрелгән кулында шәмәхәләре уңа төшкән «Женя» сүзе аша исемен дә белеп өлгерәм. Хәер, бәлки, яшьлек мәхәббәтенең исеме шулай булгандыр. Анысы миңа нигә инде? Нигә миңа болар? Әтиемнең соңгы еллары узган әлеге дөньядан тизрәк китәсем килә. Бу минем дөньям түгел. Бу – минем атам ялгышып барып эләгеп, аның соңгы сүзләрен йоткан мәрхәмәтсез дөнья.

Машинамның алгы утыргычында әтиемнән калган тальян гармун моңаеп бара. Барыбер уйнаучы юк, дип биреп җибәрде аны Әухәди карт. Үләренә берничә көн калгач, төне буе гармунында уйнап утырган икән. Уйнаган да елаган, уйнаган да елаган...

Салкын чишмә буйларында
Атлар эчерсәң иде.
Туган-үскән илләреңдә
Гомер кичерсәң иде.

Нигә китә кеше кендек каны тамган туган җиреннән? Шулай өзгәләнеп, йөрәген телгәли-телгәли яшәмәсә булмыймы? Күз алдыма җимерек йорт капкасына сөялеп карап калган Әухәди карт килеп баса. Әтиемнең җырын ул тыңлаган, авызына суны ул салган. Аны кем тыңлар?

Ә мине?..

КИЛЕШУ

Ленар җәйне авылда үткәрде. Тик әбисе ничек тә ашатырга белмәде аны. Берзаман әбекәйнең башына хәйлә килә. Оныгына пилмән пешерә дә болай ди: «25 пилмән ашасаң, бүген көне буе ял итәрсең, берни эшләмәссең. Килештекме?» «Әлбәттә, килештек!» – ди Ленар һәм тырыша-тырыша пилмән ашый башлый. Үзе ашый, үзе саный. Килешүне үтәргә кирәк. Уен эш түгел! 21, 22, 23, 24… Ә 25 нче пилмән кайда соң? Шунда Ленарның башына суга: әбисе 24 кенә пилмән пешергән икән бит! Малай алданганын аңлап ала. Әмма кемгә үпкәлисең? Килешү буенча берәү дә монда 25 пилмән дип әйтмәде. Ленар җиңен сызгана да йорт эшләренә чыгып китә. Сезгә гыйбрәт өчен бу, дуслар. Бүген күп кенә килешү-договорлар бик хәйләкәр төзелә. Кул куяр алдыннан барысын да җентекләп укыгыз, өйрәнегез һәм… пилмән турындагы бәянне искә төшерегез.

Әз-мәз мәзәк

Кәрәзле элемтә кибетендә:
– Яңа клиентлар өчен бездә уңайлы шартлар каралган.
– Ә иске клиентлар нишли?
– Алар болай да түли бит.

***

– Син нинди машинада йөрисең?
– Внедорожник минем.
– Туктале, «Лада Гранта» кайчан внедорожникка әйләнде?
– Соң, авылыбызда юллар булмагач, внедорожник инде.

***

Мин – программист. Шуңа күрә электрон билетларны һәрвакыт кәгазьгә чыгарып, үзем белән алам.

***

– Иремне кибеткә җибәрдем дә телефонымны сүндердем. Мөстәкыйльлеккә өйрәтәм.

***

– Эти, мин права алдым!
– Синең машинаң юк бит.
– Хәзер инде синең машинаң юк.

Сканворд җаваплары

Горизонталь: бишек, Лаеш, Лерон, ишәк, кол, Бәкер, Вәли, камка, Ык, Киев, Лия, тылсым, Кандыр, Бари, Әйшә, ипи, Кеша, Гарик, йа, ураза, Яна, госел, молл, бала, Али, атыш, таза, акула, Ленар, мәл, Ширин, Абба, хаин, Йә, ир, без, Ока, Идрис.

Вертикаль: Акакий, бал, апара, Имәни, Агата, балык, ар, Әлфинә, ирексез, ахири, кыя, амбар, беләзек, Баулы, әби, Ор, ишек, та, Алан, ки, сырганак, бас, Егоров, ЛиАЗ, Лукойе, Ләис, Рамил, әзер, аш, икмәк, Ла, ялтыр, Метшин, арыш.

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Беләсең килсә…

1 СССР урта мәктәпләрендә югары сыйныфларда укуны кайсы елдан түләүле итәләр?
а) 1940;
б) 1945;
в) 1950.

2 «Читен дә соң артык һичбер вакыт күрешмәсне сизеп аерылу». Бу сүзләрнең авторы кем?
а) Хәсән Туфан;
б) Муса Җәлил;
в) Абдулла Алиш.

3 «Бер картина музее» кайда урнашкан?
а) Воронеж;
б) Сыктывкар;
в) Пенза.

4 Тойгер нәрсә ул?
а) эт токымы;
б) арыслан токымы;
в) песи токымы.

Җаваплар: 1. а); 2. б); 3. в); 4. в).

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ, ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 14047 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 322

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+